# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 7

**ИЮЛЬ**

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 7*

*июль*

*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1150 нөсхә. Заказы №002588
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хөзмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 1999

## Эчтәлек

# I

590.«Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында«*Татарстан Республикасы Законы* ........ 8
591.«Сатудан салым турында«*Татарстан Республикасы Законы* ......... 28
592.«Хәйрия эшчәнлеге турында«*Татарстан Республикасы Законы* .... 35
593.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 47
594.«Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 49
595.«Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 49
596.«Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында ....... 50
597.«Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 51
598.«Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында .................... 51
599.«Татарстан Республикасының кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 52
600.«Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында» Татарстан Республикасы Югары Советы карарына үзгәрешләр кертү урында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* 53
601.«Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 54
602.«Косовода, Югославия Союз Республикасы, иминлек урнаштыру буенча халыкара катнашуда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби формированиеләрен файдалану турында» Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы карар кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Белдерүе хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 54
603.«Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитеты рәисе урынына А.П.Гусев кандидатурасын килештерү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 57
604.«М.Г.Әхмәтовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» *Татарстан*

*Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 57
605.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы составындагы үзгәреш турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 58
606.«С.А.Когогинның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында ........................ 59
607.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясе составындагы үзгәрешләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................ 59
608.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 60
609.«Татарстан Республикасы Конституциясенең 86, 153 статьяларының һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешенең үтәлеше турында Татарстан» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* Республикасы Прокуратурасы мәгълүматы хакында ........................ 64
610.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 14 июлендәге утырышы көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 65
611.«Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законын 1999 елда гамәлгә ашыруның барышы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 66
612.«Татарстан Республикасы Тукай районының Иске Дөреш җирле үзидарәсенең Яңа Абдул авылын һәм Калмия җирле үзидарәсенең Батрак авылын исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 67
613.«Татарстан Республикасы Тукай районының Әҗмәкәй җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Яңа торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 68
614.«Умартачылык турында» Татарстан Республикасы Законы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................ 68
615.«Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 69
616.«Физик культура һәм спорт турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 69
617.«Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында ........ 70
618."Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 71
619.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер карарлары үтәлеше вакытын озайту турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 71
620.«Казан шәһәрендә йөзмә күпергә автомагистраль төзегәндә

табигатьне саклау законнарының үтәлеше турында»гы мәсьәлә буенча мәгълүмат хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 72
621.«Мөселманнар өчен балалар тудыру йортлары ачу турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.Г.Шәймәрдановның гарызнамәсе хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 73
622.«Су белән тәэмин итү һәм су бирү буенча коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә норматив актларны үтәү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок гарызнамәсе хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 73
623.«Халыкны эш белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясын үтәү хакында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок гарызнамәсе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 74
624.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында ........ 74
625.Татар телендәге телерадио тапшыруларны саклау һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелүче чаралар турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 76
626.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1997 елның 22 маендагы 1174 номерлы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасын үтәүнең барышы хакында»гы карарының 2000 елга кадәр Татар дәүләт милли университетын ачу өлешен үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 77
627.«1998 елда Татарстан Республикасының республика бюджеты үтәлеше турындагы хисапны раслау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 77
628.«1999 елның 6 аенда Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 78
629.«Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 78
630.«Мактаулы ана» Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 79
631.«Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 80
632.«Татарстан Республикасының юмалар судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 80
633.«Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр, пикетлар оештыру һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 81

634. «Искергән торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 82
635. «Төсле металл ватыкларын кабул итү, исәпкә алу һәм реализацияләү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 83
636. «Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* 83
637. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе составындагы үзгәреш турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................... 84
638. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның июненә кадәр чордагы эше турында хисабы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................... 85
639. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан алып 1999 елның июленә кадәрге чор өчен хисабы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................... 85
640. «Татарстан Республикасы халык депутаты И.С.Абдуллинның «Торак бинасына техник хезмәт күрсәткән өчен түләүнең дифференциацияләнгән ставкалары турында» гарызнамәсе хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................... 86
641. «Татарстан Республикасы халык депутаты С.И.Кириловның «Хәрби хезмәттән запаска яисә отставкага җибәрелгән, республикада яшәүче гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин итү турында» гарызнамәсе хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................... 86

## II

642. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ..................... 87
643. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ... 87
644. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ... 89
645. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ..................... 90
646. «1999 елның 14 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ..................... 91
647. «1999 елның 14 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ........ 92
648.«Төзелә торган һәм төзелеп беткән индивидуаль торак йортларны (коттеджларны) исәпкә алу, бәяләү һәм төркәү тәртибен бозган өчен физик затларның административ җаваплылыгы турында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре хакында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ........ 93
649.«Татарстан Республикасы Югары суды тарафыннан кертелгән "Татарстан Республикасында юмалар судьялар турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ........ 94
650.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июнендәге утырышында Татарстан Республикасы халык депуталары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр турында» *Татарстан Республикасы Президиумы Дәүләт Советы карары* ........ 94
651.«Татарстан Республикасы икътисады өчен стратегик әһәмияткә ия предприятиеләр акцияләре әйләнешенең аерым тәртибе турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 96
652.«Татарстан Республикасы территориясендәге металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгаруны җайга салу чаралары турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 98

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 590. Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституциясе, «Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр хакында» Федераль закон, «Җир асты байлыклары турында», «Нефть һәм газ турында» Татарстан Республикасы законнары, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләрне чикләү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә минераль чималны, беренче чиратта углеводородны эзләүгә, аңа разведка ясауга һәм аны чыгаруга продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында кертелүче инвестицияләрне, шул исәптән чит илләрнекен дә, гамәлгә ашыру барышында килеп чыгучы мөнәсәбәтләрнең хокукый нигезләрен билгели.

#### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр**

Әлеге Законда түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1. «Оператор» - Татарстан Республикасы территориясендә эшләр башкаруны килешү буенча оештыру өчен, шул исәптән килешү буенча аерымланган исәпкә алу һәм хисап алып бару өчен инвестор тарафыннан җәлеп ителгән юридик зат яисә чит ил юридик заты.

2. «Чыгару» - килешү территориясе чикләрендә җир астыннан минераль чимал чыгару максатындагы барлык операцияләр һәм аңа кагылышлы гамәлләр, моңа бу гамәлләргә кагылышлы барлык корылмаларны эксплуатацияләү һәм ремонтлау да керә.

3. «Ятмаларны эшкәртү» - килешү нигезендә турыдан-туры яисә башкача минераль чимал ятмаларын эшкәртүгә, минераль чимал чыгару өчен кирәкле объектларны төзү һәм монтажлауны тәэмин итүгә һәм аны бүлешү пунктына китереп торуга бәйле эшләр. Ятмаларны эшкәртү эшләренә проект-эзләнү, төзелеш, төзү-монтаж, катламнарны ачу, бораулау эшләре, скважиналар бораулау өчен платформалар, мәйданнар, аерым нигезләр төзү, катлам суларын агызу өчен скважиналар, агып чыккан калдыкларны күмү урыннары төзү, нефть һәм газ промыселларының җыелма линияләрен төзү, сепараторлар, резервуарлар, суыртып агызу системалары, скважиналарны һәм башка объектларны механикалаштырылган эксплуатацияләү чаралары төзү, нефть һәм газ промысellары җайланмаларын, газ эшкәртү объектларын төзү, юллар, су юллары салу, электр үткәрү һәм элемтә линияләре төзү, чыгарылган минераль чималны бүлешү пунктына китереп тору өчен кирәкле объектларны төзү һәм монтажлау, әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру һ.б. керә.

4. «Продукцияне бүлешү пунктлары» - инвесторның магистраль торба үткәргеч транспорт системаларына углеводородлар тапшыру пунктлары, продукцияне төяү-бушату пунктлары (портлар, эстакадалар, складлар һәм продукция саклауның резервуар парклары), тапшырылучы продукцияне үлчәү тәэмин ителүче экспорт пунктлары.

5. «Углеводородлар» - эшкәртелмәгән нефть, нефтьтән һәм газдан алынган дистиллятларны һәм коденсатларны кертеп, скважина тамагында яисә технология аппаратурасының чыгу юшкәсендә сыек килеш калган теләсә-нинди углеводородлар.

6. «Килешү буенча эшләр» - килешүне үтәгәндә, инвестор, оператор яисә подрядчы тарафыннан башкарылучы һәм махсус банк счетларыннан финансланучы (түләнүче) эшләр, хезмәт күрсәтүләр, операцияләр һәм башка гамәлләр. Минераль чимал запасларын эзләүгә һәм бәяләүгә, ятмаларга разведка ясауга һәм эшкәртүгә, минераль чимал чыгаруга, бетерү эшләре үткәрүгә ярдәмче һәм хезмәт күрсәтү эшләрен дә кертеп, турыдан-туры бәйле булмаган, шулай ук әгәр инвестор, оператор яисә подрядчы кешеләр тормышын, сәламәтлеген һәм әйләнә-тирә мохитне яклау өчен нигезләнгән эшләр башкарган очракта, табигый бәла-казаларга бәйле булганнарыннан тыш, теләсә-нинди бүтән эшләр килешү буенча башкарылучы эшләргә кертелә алмый.

7. «Чыгымнар сметасы» - инвесторның әлеге Законның II бүлеге килешү һәм килешү шартлары буенча ел саен әзерләнә торган вәкаләтле дәүләт органы яисә килешү шартлары нигезендә һәм төзелүче идарә итү комитеты тарафыннан расланучы чыгымнар сметасы. Чыгымнар сметасында эшләр программасы нигезендә, эш төрләре, чыгымнар һәм чыгымнарның элементлары буенча киметү эшләренең еллык чыгымнарына хакын күрсәтеп бәяләү күздә тотыла.

8. «Җитештерелгән продукция» - минераль чималның бүлешү пунктына кадәр булган норматив югалтуларын һәм инвесторның үз технологик ихтыяҗларына тотылган минераль чималның норматив чыгымын алганнан соңгы, чыгарылган минераль чималның бүлешү пунктындагы күләме.

9. «Бонуслар» - килешү төзегәндә (имза салу бонусы), шулай ук килешү шартлары нигезендә билгеле бер нәтиҗәгә ирешкәндә инвестор тарафыннан бер мәртәбә түләнүче акча (кертемнәр, акча күчерүләр, компенсация).

10. «Исәпкә алу валютасы» - инвесторның чыгымнарын кире кайтару һәм килешү буенча салым салынучы табышны исәпләп чыгару максатларында килешү буенча эш алып баруга чыгымнар һәм җитештерелгән продукциянең хакы турында килешү шартлары нигезендә бухгалтер исәпкә алуын һәм хисабын алып бару өчен кабул ителгән Россия Федерациясе валютасы (рубльләрдә) яисә чит ил валютасы.

11. «Кире кайтарылучы чыгымнар» - инвестор тарафыннан килешү буенча эшләр башкаруга тотылган һәм тиешле чорга чыгымнарның үтәлгән сметасына кертелгән нигезле чыгымнар, алар инвестор алган компенсация продукциясе исәбеннән әлеге Закон нигезендә килешүдә билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

2 статья. **Әлеге Закон белән җайга салынучы мөнәсәбәтләр**

1. Закон Татарстан Республикасы территориясендә продукция бүлешү турында килешүләр төзү, үтәү һәм туктату барышында килеп чыккан мөнәсәбәтләрне җайга сала, җир асты байлыкларын нәтиҗәле геологик өйрәнүне, табигый ресурс ятмаларын оптималь эшкәртүне гарантияләүче мондый килешүләрнең төп хокукый шартларын билгели, Татарстан Республикасы халкының һәм инвесторларның мәнфәгатьләрен яклый.

2. Әлеге Закон белән җайга салынмаган, шул исәптән җирләрдән һәм башка табигый ресурслардан (углеводородлардан тыш) файдалану барышында килеп чыгучы мөнәсәбәтләр, шулай ук, чыгарыла торган металларга, ташларга (кыйммәтле ташларны да кертеп), радиоактив чималга милек хокукын чикләүләрне яисә тыюларны исәпкә алып, әлеге Законны куллану үзенчәлекләре Татарстан Республикасының башка законнары һәм бүтән норматив-хокукый актлары белән, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләрне бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсендә каралган очракларда исә, - Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән җайга салына.

3. Ятмаларны геологик өйрәнү, эшкәртү, транспортлау, саклау, яңадан эшкәртү, файдалану, сату, продукцияне бүлешүне һәм бүтәнчә эш итүне дә кертеп, минераль чималны эзләү, разведка ясау һәм чыгару барышында килеп чыгучы мөнәсәбәтләр продукцияне бүлешү турында әлеге Закон нигезендә төзелүче тиешле килешү белән җайга салына.

Продукцияне бүлешү турындагы килешү якларының граждан-хокукый характердагы хокуклары һәм бурычлары әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган граждан законнары нигезендә билгеләнә.

3 статья. **Продукцияне бүлешү турында килешү**

1. Продукцияне бүлешү турында килешү (алга таба - килешү) шундый шартнамә ки, аның нигезендә Татарстан Республикасы, дәүләт буларак, эшкуарлык эшчәнлеге субъектына (алга таба - инвестор) килешүдә күрсәтелгән җир асты кишәрлегендә углеводородларны һәм башка минераль чималны эзләү, разведка ясау, чыгару өчен һәм шуларга бәйле эшләрне башкару өчен түләүсез нигездә һәм билгеле бер чорга махсус хокуклар тапшыра, ә инвестор исә үз исәбенә һәм, үзе тәвәккәлләп, күрсәтелгән эшләрне башкарырга йөкләмә ала. Килешү җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле барлык кирәкле шартларны, шул исәптән килешү яклары арасында продукцияне әлеге Закон нигезләмәләре нигезендә бүлешү шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Җир асты байлыкларыннан файдалануның килешүдә билгеләнгән шартлары «Нефть һәм газ турында», «Җир асты

байлыклары турында» Татарстан Республикасы законнары таләпләренә каршы килмәскә тиеш. Җир асты байлыкларыннан продукцияне бүлешү турындагы килешү шартларында файдалануга лицензия әлеге Законның 5 статьясы нигезләмәләре нигезендә бирелә һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатып торылырга мөмкин.

3. Продукцияне бүлешү шартларында әлеге Закон нигезләмәләре нигезендә файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган җир асты кишәрлекләре исемлеге Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә һәм моңа чыгарылучы нефть запаслары 25 миллион тоннага кадәр булган ятмалар кертелә. Татарстан Республикасының күрсәтелгән закон проектлары, шулай ук шушы законнарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы закон проектлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә.

4. Продукцияне бүлешү шартларында файдалану хокукы булган җир асты кишәрлекләрен исемлеккә кертү өчен түбәндәгеләр нигез була:

- файдалы казылма ятмаларын, чыганакларын яисә аның мөстәкыйль эшкәртелүче өлешләрен (файдалы казылмаларның эре чыганаклары өчен) эшкәртүне дәвам итүнең җир асты байлыкларыннан файдаланучы һәм дәүләт өчен зыян китерүгә файдалы казылмаларны шактый күләмдә чыгаруны һәм шәһәр барлыкка китерүне тәэмин итә торган объектив факторларга бәйле булуы, шуңа күрә файдалы казылмалар чыгаруны туктату тискәре социаль нәтиҗәләргә бәйле була;

- тулаем Татарстан Республикасы буенча һәм, беренче чиратта, аның ерак һәм аз үзләштерелгән районнарында җир асты кишәрлекләрен, минераль чимал чыгару дәрәҗәсен саклап калуны тәэмин итүче файдалы казылмаларның ятмаларын, чыганакларын эшкәртү, аларны геологик өйрәнү һәм үзләштерү өчен, республиканың социаль үсеше, милли һәм икътисадый иминлеге өчен инфраструктура объектлары төзү өчен финанс һәм техник чараларның булмавы;

- катлаулы геологик-тау шартларындагы файдалы казылмаларның кыен чыгарыла торган запасларын эшкәртү өчен, шулай ук җир асты байлыкларыннан эксплуатацияләнүче чыганакларындагы минераль ресурсларның калган запасларын бөтенләй юкка чыгудан саклап калу өчен махсус технология-

ләрне җәлеп итү зарурлыгы;

- махсус сакланылучы табигать территорияләрендә һәм санитар-яклау зоналарында урнашкан файдалы казылмалар чыганакларын эшкәрткәндә экологик иминлекне һәм җир асты байлыклары сакланышын тәэмин итү өчен шактый гына өстәмә акчалар тоту зарурлыгы;

- халыкның эш белән тәэмин ителеше түбән булган районнарда яисә дотация бирелә торган районнарда үзебезнең ягулык-энергетика чималы белән тәэмин итү, яңа производстволар булдыру, углеводородлар чыгаруны тотрыкландыру, социаль киеренкелекне киметү зарурлыгы.

5. Продукцияне бүлешү шартларында җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга тапшыру турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты керткән тәкъдимнәр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителә.

6. Әлеге Закон үз көченә кергәнче төзелгән килешүләр аларда билгеләнгән шартлар нигезендә үтәлергә тиеш. Бу чакта әлеге Закон нигезләмәләре күрсәтелгән килешүләргә карата мондый килешүләрнең шартларына каршы килми торган һәм бу килешүләр нигезендә инвесторлар тарафыннан алынган һәм гамәлгә ашырылучы хокукларны чикләми торган дәрәҗәдә кулланыла.

4 статья. **Килешүнең яклары**

Түбәндәгеләр килешүнең яклары булалар:

- дәүләт (Татарстан Республикасы), килешүдә аның исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яисә ул вәкаләт биргән орган эш йөртә;

- инвесторлар - нефть һәм газ эзләүгә, разведка ясауга һәм чыгаруга үз акчаларын, заем яисә җәлеп ителгән акчаларны кертүче һәм килешү шартларында җир асты байлыкларыннан файдаланучы Татарстан Республикасы гражданнары, Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, юридик затлар һәм коммерция оешмаларының һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның юридик зат статусына ия булмаган берләшмәләре.

5 статья. **Продукцияне бүлешү шартларында җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану**

1. Продукцияне бүлешү шартларында җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы әлеге Закон

нигезендә төзелгән килешү буенча инвесторга продукция бүлешү шартларында бирелә.

2. Җир асты байлыклары кишәрлеге файдалануга килешү шартлары нигезендә тапшырыла. Бу вакытта җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын раслый торган лицензия инвесторга килешүгә имза салынган көннән соң 30 көн эчендә Җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү буенча республика органы тарафыннан бирелә. Күрсәтелгән лицензия килешүнең гамәлдә булу чорына бирелә һәм озайтылырга яисә яңадан рәсмиләштерелергә мөмкин, йә ул килешү шартлары нигезендә үз көчен югалта.

3. Инвестор буларак юридик зат статусына ия булмаган юридик затлар берләшмәсе эш иткән очракта, 2 пунктта күрсәтелгән лицензия вәкаләтле затка - мондый берләшмәнең катнашучыларыннан берәрсенә бирелә, бу лицензиядә вәкаләтле затның берләшмә исеменнән эш итүе, шулай ук берләшмәнең башка барлык катнашучылары күрсәтелә.

6 статья. **Килешүнең гамәлдә булу чоры**

1. Килешүнең гамәлдә булу чоры законнар нигезендә яклар тарафыннан килешүдә билгеләнә.

2. Килешүнең гамәлдә булуы инвесторның үзенә алган йөкләмәсе үтәлгән шартларда якларның үзара килешүе буенча озайтылырга мөмкин, әмма бу вакыт баштагы килешүдә билгеләнгән вакыттан артмаска тиеш.

Бу чакта килешүнең вакытын озайту әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Килешүнең гамәлдә булу чоры озайтылганда Татарстан Республикасының әлеге Законының 5 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясе шушы лицензияне биргән орган тарафыннан озайтылырга тиеш.

## II бүлек. Килешүләрне төзү һәм үтәү

7 статья. **Килешүне төзү тәртибе**

1. Килешү законнарда билгеләнгән тәртиптә үткәрелүче конкурста яисә аукционда җиңүче һәм яклар килештергән чорга, әмма аукцион яисә конкурс нәтиҗәләрен игълан иткән көннән бер елдан да соңга калмыйча, дәүләт тарафыннан төзелә, моңа әлеге статьяның 2 пунктында каралган очраклар керми.

Килешү законнар нигезендә төзелә. Конкурс яисә аукцион үткәрмичә генә җир асты байлыкларыннан файдаланучылары булмаган җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата төзелгән килешүләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан расланалар.

2. Килешүләр конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә төзелергә мөмкин, әгәр дә:

- Татарстан Республикасының милли иминлеге мәнфәгатьләре конкрет инвестор белән килешү төзүне таләп итсә;

- әлеге Законның 3 статьясындагы 3 пункты нигезендә җир асты байлыклары кишәрлекләренең исемлеген билгеләүче тиешле нигезләмә Татарстан Республикасы законы белән каралса;

- игълан ителгән конкурс яисә аукцион анда бер генә инвестор катнашканга күрә үткәрелмәгән дип табылса. Мондый очракта килешү бу конкурста яисә аукционда катнашкан шушы инвестор белән конкурс яисә аукцион шартларында төзелергә мөмкин;

- инвестор килешүдәгедән үзгәрәк шартларда, Татарстан Республикасы законнарында каралган башка шартларда әлеге Закон гамәлгә кергән көнгә казылма байлыкларга разведка ясау һәм аларны чыгару буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучы булса. Бу очракта килешү җир асты байлыкларыннан файдаланучының шунысы белән йә шушы файдаланучы катнашында оештырылган башка юридик зат белән төзелә;

- Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының инвестор белән килешүләрнең проектларын әзерләү турындагы сөйләшүләре әлеге Закон гамәлгә кергәнче башланган булса.

Күрсәтелгән очракларда килешүләр яклар тарафыннан килешенгән чорларда, әмма Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карар кабул иткәннән соң бер елдан да соңга калмыйча төзелә.

3. Җир асты байлыкларыннан файдалану шартларын әзерләүне һәм җир асты байлыкларыннан файдалануның һәр объекты буенча килешү проектын әзерләүне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты төзегән комиссия башкара. Күрсәтелгән комиссия составына дәүләт идарәсе органнарының һәм (килешү буенча) дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнарының вәкилләре керәләр. Кирәк очракларда күрсәтелгән

комиссия эшенә җитештерү һәм фәнни оешмалар, шулай ук экспертлар һәм консультантлар җәлеп ителәләр.

Килешү проекты җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклауның Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрен күз алдында тотарга тиеш.

4. Дәүләт ягыннан килешүгә имза салуны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты гамәлгә ашыра.

5. Килешүгә яклар тарафыннан килешенгән вакытларда, якларның вәкаләтле делегацияләре арасында сөйләшүләр тәмамланганнан соң имза салына, алар нәтиҗәсендә килешүнең конкурс яисә аукцион өчен мәҗбүри булмаган барлык кирәкле шартлары килештерелергә тиеш. Бу чакта конкурс яисә аукционның мәҗбүри шартлары килешү шартларына каршы килмәскә тиеш.

8 статья. **Эшләрне үтәү шартлары**

1. Килешүдә каралган эшләр һәм эшчәнлек төрләре (алга таба - килешү буенча эшләр) килешүдә билгеләнгән тәртиптә программалар, проектлар, планнар һәм сметалар нигезендә үтәләләр.

2. Килешү буенча эшләр Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәгән килеш, шулай ук эшләрне алып баруның иминлеге, җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә табигать мохитен һәм халыкның сәламәтлеген саклауның законнар белән билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларын (нормаларын, кагыйдәләрен) үтәгән килеш гамәлгә ашырылалар. Бу чакта килешүдә инвесторның түбәндәгеләр буенча йөкләмәләре күз алдында тотыла:

- Татарстан Республикасында теркәлгән юридик затларга килешү буенча эшләрне үтәүдә подрядчылар, китереп торучылар, йөк ташучылар буларак катнашуга яисә инвесторлар белән шартнамәләр (контрактлар) нигезендә башка сыйфатта катнашуга өстенлекле хокук бирү;

- Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнар арасында тиешле квалификацияле белгечләр булмаганда чит ил эшчеләрен һәм белгечләрен килешү буенча эшләрнең башлангыч этапларында, аларның санын һәм эш вакытын күрсәтеп, җәлеп итү;

- тиешле эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Россия юридик затлары яисә чит ил юридик затлары арасында заказларның гомуми хакы күләмен килешүдә билгеләп, конкуренциягә

сәләтле җиһазлар, файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, чыгару һәм беренчел эшкәртү өчен кирәкле техник чаралар һәм материаллар әзерләүгә заказлар урнаштыру;

- килешү буенча эш йөртү өчен яңа техника сатып алуның һәм прогрессив технологияләрне гамәлгә кертүнең конкурс принцибы;

- инвестиция акчалары нефть ятмаларын эшкәртү буенча капитал салуларга җибәрелмәгәндә, Татарстан нефть компанияләренең акцияләрен алудан баш тарту;

- инвесторы чит илнеке булган очракта, Татарстанның теләсә нинди нефть компаниясе чыгарган акцияләрнең гомуми саныннан 25 проценттан артыграк акцияләр сатып алудан баш тарту;

- әлеге эшләрнең әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынтысын кисәтүгә, шулай ук андый йогынтының нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру;

- әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынты китереп чыгарган һәлакәт очракларында зыянны каплау буенча җаваплылыкны иминләштерү;

- килешү буенча, шулай ук килешү нигезендә эш башкарылган территорияне пычранудан чистарту буенча эшләр төгәлләнгәч, кирәк булганда барлык корылмаларны, җайланмаларны һәм башка мөлкәтне юк итү.

3. Килешү буенча эшләрне башкаруны оештыру, шул исәптән әлеге Законның 15 статьясы нигезләмәләренә туры китереп исәпкә алуны һәм хисаплылыкны алып бару инвестор тарафыннан яисә инвестор кушуы буенча килешү операторы тарафыннан башкарыла. Эшчәнлеге әлеге эшләрне оештыру белән чикләнергә тиешле мондый оператор сыйфатында Татарстан Республикасы территориясендә әлеге максатлар өчен инвестор тарафыннан төзелүче филиаллар яки инвестор тарафыннан әлеге максатлар өчен җәлеп ителүче юридик затлар, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкаручы һәм бу территориядә салым түләүчеләр буларак теркәлгән чит ил юридик затлары эш йөртә. Монда инвестор оператор гамәлләре өчен дә, үз гамәлләре өчен дә дәүләт алдында мөлкәти җаваплылыкка ия.

4. Минераль чимал чыганакларын эзләүнең һәм разведка ясауның аерым этаплары тәмамланганда инвестор шартнамә шартлары нигезендә үзенә файдалануга бирелгән территория

кишәрлекләрен кайтарып бирергә тиеш. Кайтарып бирелүче кишәрлекләрнең күләме, шулай ук аларны кайтарып бирү тәртибе, вакыты һәм шартлары килешү белән билгеләнә.

5. Үзләрендә килешү буенча эшләр уздырыла һәм файдалы казылмалар чыгару күздә тотыла торган объектлар буенча геологик һәм техник-икътисадый мәгълүмат законнар нигезендәге тәртиптә һәм күләмдә дәүләт экспертизасына бирелергә тиеш.

6. Килешү буенча эшләрне башкару өчен эшчәнлекне координацияләү максатларында яклар тарафыннан идарә итү комитеты төзелү каралырга мөмкин, аның составына һәръяктан бертигез санда вәкилләр кертелә. Идарә итү комитетының сан составы, хокуклары һәм бурычлары, шулай ук аның эшләү тәртибе килешү белән билгеләнә. Килешү буенча эшләрне башкару өчен эшчәнлекне координацияләүнең башка рәвешләрендә идарә итү органнарында дәүләт вәкиленең булуы мәҗбүри.

9 статья. **Продукцияне бүлешү**

Җитештерелгән продукция дәүләт һәм инвесторлар арасында килешү нигезендә бүленергә тиеш, анда түбәндәге шартлар һәм тәртип каралырга тиеш:

- җитештерелгән продукциянең һәм аның бәясенең гомуми күләмен билгеләү;
- җитештерелгән продукциянең килешү буенча эшләрне үтәүгә чыгымнарын каплау (моннан ары - компенсация продукциясе) өчен инвесторга милек итеп бирелә торган өлешен билгеләү (шул исәптән аның ахыр чик дәрәҗәсен дә). Бу очракта инвесторга компенсация продукциясе исәбеннән түләнергә тиешле чыгымнар составы килешү белән билгеләнә;
- Татарстан Республикасы һәм инвестор арасында керемле продукцияне, монда әлеге продукциянең бер өлеше алынганнан соң әлеге закон нигезләмәләре нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрдә файдаланылучы җитештерелгән продукция күздә тотыла, һәм компенсация продукциясен бүлешү;
- Татарстан Республикасына җитештерелгән продукциянең килешү шартлары нигезендә аңа тиеш булган өлешен яисә аның бәясе эквивалентын тапшыру;
- килешү шартлары нигезендә инвесторның үзенә тиешле җитештерелгән продукцияне алуы.

### 10 статья. **Инвесторның җитештерелгән продукциягә милек хокукы**

1. Компенсация продукциясе, шулай ук керемле продукциянең килешү шартлары нигезендә инвестор өлеше булып торучы бер өлеше, милек хокукында инвесторныкы була.

2. Килешү шартлары нигезендә инвестор милкенә керүче минераль чимал Татарстан Республикасы территориясеннән һәм Россия Федерациясе таможня территориясеннән әлеге килешү белән билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә чыгарыла ала.

### 11 статья. **Җитештерелгән продукциянең дәүләт өлешен бүлү һәм сату**

1. Җитештерелгән, килешү шартлары нигезендә продукция бүлешү нәтиҗәсендә дәүләт алган продукцияне яисә аның шул ук бәядәге эквивалентын бүлү һәр аерым килешү буенча, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башкарма хакимияте арасында төзелүче шартнамәләр нигезендә, кагыйдә буларак, андый килешүнең үз көченә кергәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча, башкарыла.

Әлеге шартнамәләр түбәндәгеләрне билгели:

- җитештерелгән продукциянең файдалануга бирелүче җир асты байлыклары кишәрлекләренең урынын, чыгарылучы минераль чимал төрләрен һәм аның чыгарылучы запаслары күләмен, дәүләт һәм инвестор арасында продукцияне бүлешкәндә исәпкә алынучы һәм федераль бюджетка түләнергә тиешле салымнар зурлыгын, килешү буенча эшләр башкарыла торган территорияләрнең социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсен, экологик хәвефлелек дәрәҗәсен исәпкә алып билгеләнүче дәүләт өлешен бүлешү пропорциясен;

- җитештерелгән продукциянең Татарстан Республикасы милкенә һәм федераль милеккә бүленүче дәүләт өлешен килешенгән пропорцияләр нигезендә әлеге продукциянең яисә аның бәя эквивалентының (салымнарны да кертеп) керү шартларын һәм тәртибен.

2. Җитештерелгән продукциянең Татарстан Республикасы милкенә керүче өлешеннән файдалану Татарстан Республикасы законнары билгеләгән тәртиптә тормышка ашырыла.

3. Җитештерелгән продукция өлешен яисә аны сатудан

Татарстан Республикасы милкенә керүче табышны бүлешү тәртибе республика бюджетын раслаганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

12 статья. **Мөлкәткә һәм мәгълүматка милек хокукы**

1. Яңа барлыкка китерелгән яисә инвестор тарафыннан сатып алынган һәм аның тарафыннан килешү буенча эшләр башкаруда файдаланылучы мөлкәт, әгәр килешүдә башкасы каралмаса, инвестор милке булып тора.

Әлеге мөлкәткә милек хокукы әлеге мөлкәтнең бәясе тулысынча кайтарылган көннән яисә килешү туктатылган көннән яисә килешүдә каралган шартларда һәм тәртиптә яклар белән килештерелгән башка көннән инвестордан дәүләткә күчә. Бу очракта килешү гамәлдә булган вакыт дәвамында андый мөлкәттән файдалануга аерым хокук килешү буенча эшләр башкару өчен түләүсез нигездә бирелә һәм инвестор үзе файдалана торган мөлкәтне тоту мәшәкатьләрен һәм аның очраклы төстә юк ителүе һәм очраклы төстә зарарлануы куркынычын үз өстенә ала.

2. Барлык башлангыч геология, геофизика, геохимия һәм башка мәгълүмат, аны интерпретацияләү белешмәләре һәм аннан килеп чыгучы белешмәләр, шулай ук инвестор тарафыннан килешү буенча эш башкарганда алынган тау токымнары үрнәкләре, шул исәптән керн, катлам сыекчалары милек хокукында дәүләтнеке була. Килешүдә каралган конфиденциальлек шартларын үтәгәндә, инвестор килешү буенча эш башкару максатларында әлеге мәгълүмат, белешмәләр һәм үрнәкләр белән иркле һәм түләүсез файдалану хокукына ия. Әлеге мәгълүматтан, белешмәләрдән һәм үрнәкләрдән файдалану тәртибе, шулай ук аларны Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе чикләреннән алып чыгу тәртибе закон нигезендә килешү белән билгеләнә.

13 статья. **Минераль чималны транспортлау, саклау һәм эшкәртү**

1. Инвестор шартнамә нигезендә торбаүткәргеч транспорты объектларына иркле керү хокукына, шулай ук шартнамә нигезендә нинди дә булса дискриминацияле шартларсыз торбаүткәргеч һәм башка төр транспорттан файдалану, минераль чималны саклау һәм эшкәртү объектларыннан

файдалану хокукына ия.

2. Килешү буенча эш башкару кысаларында инвестор минераль чималны саклау, эшкәртү һәм транспортлау объектлары коруга хокуклы, аларга милек хокукы әлеге Законның 12 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.

### 14 статья. Килешүне үтәгәндә салымнар һәм түләүләр

1. Керемгә салымнан һәм җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрдән тыш, инвестор килешүнең гамәлдә булуының бөтен дәвамында, әлеге статьяның 4 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, законнарда каралган салымнардан, җыемнардан, акцизлардан һәм башка мәҗбүри түләүләрдән (әлеге статьяның 7 пунктында каралганнардан башка) азат ителәләр. Әлеге салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр гамәлдәге законнар нигезендә килешү шартларында продукция бүлешү белән алыштырыла.

Әгәр Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары һәм җирле үзидарә органнарының хокукый актлары белән инвесторны салымнар, җыемнар һәм Татарстан Республикасы бюджетына һәм җирле бюджетларга башка мәҗбүри түләүләрдән азат итү каралмаса, килешү шартлары нигезендә инвестор өлеше булган керемле продукциянең бер өлеше, Татарстан Республикасы бюджетына һәм җирле бюджетларга фактта түләнгән салымнар, җыемнар, башка мәҗбүри күләмнәр суммасына һәм Россия Федерациясе Үзәк банкының үткән чорда гамәлдә булган рефинанслау ставкаларыннан чыгып исәпләнгән анык суммага тигез күләмдә дәүләт өлешен тиешенчә киметү исәбенә арттырылырга тиеш.

2. Керемгә салым инвестор тарафыннан законнар билгеләгән тәртиптә түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып түләнә:

- керемле продукциянең килешү шартлары буенча инвесторныкы булган өлешенең килешү шартлары нигезендә билгеләнүче бәясе бу салымны салу объекты булып тора. Бу бәя инвесторның заем акчаларыннан файдаланган өчен түләүләре, инвесторның җир асты байлыкларыннан файдаланганга бер тапкыр түләүләре суммасына, шулай ук инвесторга килешү шартлары нигезендә кайтарып бирелмәүче башка суммаларга кимételә, аларның составы һәм исәпкә алу тәртибе керемгә салым салу объектын билгеләгәндә, законнар нигезендә килешү белән билгеләнә. Әгәр дә әлеге чыгымнар керемле продукци-

янең инвесторныкы булган өлеше бәясеннән артык булса, аннан соңгы чорларда керемгә салым салу объекты килеп чыккан тиешле аерма суммасына, ул тулысынча капланганга кадәр, киметелә;

- килешү буенча эшләр башкарганда керемгә салымны түләү башка төр эшчәнлек буенча керемгә салым түләүдән аерым башкарыла. Бу очракта керемгә салымның килешүгә кул куелган көндә гамәлдә булган ставка кулланыла;

- законнар белән каралган керемнәргә салым буенча өстенлекле ташламалар, шулай ук хезмәт өчен түләүгә чыгымнарның аларның нормаланган суммасыннан факттагы артык суммасына, түләнгән дивидендлар яисә өлешкә катнашудан керемнәр суммаларына салым салу керемгә салым салганда кулланылмый;

- Татарстан Республикасы бюджетына әлеге салымны санау ставкалары буенча алынучы керемгә салым түбәндәгечә кертелә: түләүченең теркәлгән урыны кайда булуга карамастан, Татарстан Республикасының республика бюджетына - 50 процент һәм шәһәрләр һәм районнар территорияләрендә чыгарылган файдалы казылмаларның күләменә тиң рәвештә аларның бюджетына - 50 процент.

- якларның килешүе буенча керемгә салым инвестор тарафыннан натуралата яисә бәясе рәвешендә түләнә.

3. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр законнар белән инвестор тарафыннан түбәндәгечә кертелә:

Татарстан Республикасының республика бюджетына - 50 процент һәм шәһәрләр һәм районнар территорияләрендә чыгарылган файдалы казылмаларның күләменә тиң рәвештә аларның бюджетына - 50 процент.

4. Килешү шартлары нигезендә инвесторныкы булган җитештерелгән продукцияне сатканда өстәлгән бәягә салымны санаганда тиешле вакытка бюджетка кертеләсе кертемнән әлеге салым суммасыннан бу чорда килешү буенча эш башкару өчен товар - матди кыйммәтләр буенча, шулай ук эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр буенча инвестор түләгән өстәмә бәягә салымның бөтен суммалары алып ташлана.

Сатып алына торган товар-матди кыйммәтләр өчен инвестор товар җибәрүчеләргә түләгән суммаларга әлеге салым инвестор милке булган җитештерелгән продукцияне сатканда саналган суммаларга әлеге салымнан артып китү очрагында

барлыкка килгән аерма инвесторга законнар билгеләгән тәртиптә һәм вакытта кайтарылырга тиеш, әлеге аерманың суммасы үткән тиешле вакытта гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасыннан чыгып аныклана.

Минераль чимал чыгару башланганнан соң тиешле көнгә инвесторга бюджеттан кайтарылмаган әлеге аерманың анықланган суммасы килешү шартлары нигезендә дәүләтнеке булган җитештерелгән продукцияне аның бәясенә тиң күләмдә кимету исәбенә каплана.

Килешү буенча эшләр башкару өчен кирәк булган товар-матди кыйммәтләрне түләүсез тапшыру буенча инвестор һәм килешү операторы арасындагы әйләнешләр, шулай ук килешүдә билгеләнгән тәртиптә расланган смета нигезендә әлеге эшләрне финанслау өчен кирәк булган акчаларны күчерү буенча операция өстәлгән бәягә салымнан азат ителәләр.

5. Инвестор җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен дәүләткә түбәндәгеләрне түли:

- килешү төзегәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүләр (бонуслар) һәм (яисә) билгеле бер нәтиҗәгә ирешкәннән соң түләнә торган килешүдә билгеләнгән түләүләр;

- минераль чимал чыгару күләменнән яисә җитештерелгән продукция бәясеннән процентлы чагыштырмада билгеләнгән һәм инвестор тарафыннан акчалата яисә чыгарылган минераль чимал рәвешендәге даими түләүләр.

Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен башка түләүләрдән инвестор азат ителә.

6. Җирдән һәм башка табигать ресурсларыннан файдаланган өчен түләү, Татарстан Республикасы законнарына туры китереп, шартнамә нигезендә башкарыла.

7. Инвестор Россия Федерациясе законнары нигезендә үз хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе гражданнарын социаль һәм медицина иминләштерүе буенча, шулай ук Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү дәүләт фондына һәм Россия Федерациясе пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсенә мәҗбүри түләүләрне гамәлгә ашыра.

8. Инвестор белән төзелгән шартнамәләр (контрактлар) нигезендә килешү буенча эшләр башкаруда катнашучы килешү операторлары, шулай ук юридик затлар (подрядчылар, китереп

торучылар, ташучылар һәм башка затлар) әлеге эшләрне башкару өчен билгеләнгән проект документлары нигезендә таможня территориясенә товар һәм хезмәт күрсәтүләр керткәндә өстәмә бәяләргә һәм акцизларга салым алудан, шулай ук килешү шартлары нигезендә инвестор милке булган минераль чималны һәм аны эшкәртеп алынган продуктларны таможня территориясе чикләреннән чыгарганда салым алудан азат ителәләр.

15 статья. **Исәп һәм хисап**

1. Килешү буенча эшләр башкарганда инвесторның финанс-хуҗалык эшчәнлеген исәпкә алу һәр аерым килешү буенча, шулай ук килешүгә бәйле булмаган бүтән эшчәнлек башкарылганда мондый исәптән аерым алып башкарыла. Мондый исәпнең тәртибе, шул исәптән инвесторның чыгымнарын кайтару һәм табышка салымны исәпләү максатларында, законнар нигезендә килешү белән билгеләнә.

2. Килешү буенча эшләр башкарганда бухгалтер исәбе һәм хисабы Россия Федерациясе валютасында (рубльләрдә) яисә чит ил валютасында алып барыла. Бухгалтер исәбе чит ил валютасында алып барылган очракта, дәүләт органнарына бирелә торган хисапта кабул ителгән чит ил валютасында да, рубльләрдә дә белешмәләр булырга тиеш. Бу очракта чил ил валютасында исәпләнгән барлык белешмәләр хисап төзегән көнгә Россия Федерациясе Үзәк банкы курсы буенча рубльләргә күчереп исәпләнергә тиеш.

16 статья. **Банк счетлары һәм валюта көйләве**

1. Килешү буенча эшләр башкару өчен инвестор Татарстан Республикасы территориясендәге һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясендәге, һәм (яисә) чит дәүләтләр территориясендәге банкларында рубльләрдә һәм (яисә) чит ил валютасында махсус банк счетлары булдырырга тиеш, алар фәкать әлеге эшләрне башкару өчен файдаланылырга тиешләр.

2. Инвестор килешү шартлары нигезендә үзенә тиешле продукциянең бер өлешен сатудан алынган табышны чит ил валютасында алырга һәм әлеге банк счетларында сакларга, шушы килешү буенча эшләр башкаруның теләсә нинди чыгымнарын счетлардан түләргә, шулай ук табышка салымны түләргә һәм җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрне башкарырга, әлеге счетларда калган акчалар белән ирекле эш итәргә хокуклы.

3. Инвесторга, шулай ук инвестор белән төзелгән шартнамәләр (контрактлар) нигезендә килешү буенча эш башкаруда катнашучы юридик затларга (килешү операторларына, подрядчыларга, китереп торучыларга, ташучыларга һәм башка затларга) килешү буенча эш башкарганда чит ил валютасында алынган табышның бер өлешен Россия Федерациясе валюта базарында мәҗбүри сату турындагы таләп кагылмый.

17 статья. **Килешү буенча хокукларны һәм вазыйфаларны тапшыру**

1. Инвестор килешү буенча үз хокукларын һәм вазыйфаларын тулысынча яисә өлешчә теләсә-нинди юридик затка яисә гражданга (физик затка) фәкать дәүләт ризалыгы белән генә тапшыра ала, бу очракта әлеге затларның килешү буенча эшләр башкару өчен кирәк кадәр финанс һәм техник ресурслары һәм идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе булуы шарт итеп куела.

2. Килешү буенча хокукларны һәм вазыйфаларны тапшыру килешүнең аерылгысыз өлеше булган махсус акт төзү юлы белән язмача, килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта башкарыла һәм әлеге актка имза салынган көннән соң 30 көн эчендә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан тиешенчә рәсмиләштерү белән төгәлләнә.

3. Дәүләт ризалыгы белән инвестор, законнар таләпләрен үтәп, килешүне үтәүгә бәйле төзелгән шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен тәэмин итү өчен залог сыйфатында үз мөлкәтеннән һәм мөлкәти хокуклардан файдалана ала.

18 статья. **Килешү шартларының тотрыклылыгы**

1. Килешү шартлары килешүнең бөтен гамәлдә булу чорында үз көчен саклый. Килешүгә үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә шартлар җитди үзгәргән очракта, якларның ризалыгы буенча гына, шулай ук якларның берәрсе таләбе буенча, Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларын исәпкә алып кына рөхсәт ителә.

Килешү шартларына яклар килешүе буенча кертелгән үзгәрешләр төп килешүләр тәртибендә гамәлгә кертелә (конкурстан гайре).

2. Килешү гамәлдә булган вакытта законнар һәм җирле үзидарәнең хокукый актлары белән инвесторның килешү кысаларындагы эшчәнлегенең коммерция нәтиҗәләрен

начарлатучы нормалар билгеләнгән очракта, килешүгә аны төзү вакытында гамәлдә булган законнарны һәм җирле үзидарә органнарының хокукый актларын кулланганда инвестор алырга мөмкин булган коммерция нәтиҗәләрен тәэмин итүче үзгәрешләр кертелә. Шундый үзгәрешләрне кертү тәртибе килешү белән билгеләнә.

Әгәр эшләрне хәвефсез алып бару, җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне һәм кешеләрнең сәламәтлеген саклау стандартларына (нормаларына, кагыйдәләренә), шул исәптән аларны халыкара гамәлияттә кабул ителгән һәм гомумтанылган шундый ук стандартларга (нормаларга, кагыйдәләргә) яраклаштыру максатларында, законнар белән үзгәрешләр кертелсә, килешү шартларын үзгәртү турында әлеге нигезләмә кулланылмый.

19 статья. **Инвестор хокукларына дәүләт гарантияләре**

1. Инвесторга килешү нигезендә алынган һәм аның тарафыннан тормышка ашырылучы мөлкәти һәм башка хокуклар гарантияләнә.

2. Эшләрне хәвефсез алып баруны, җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә табигать мохитен, кешеләр сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, шулай ук җәмәгать һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү максатларында, тиешле күзәтеп тору органнарының законнар нигезендә бирелүче күрсәтмәләреннән гайре, инвесторларның килешү нигезендә алынган һәм гамәлгә ашырыла торган хокукларын чикләүне билгели торган законнарның һәм бүтән норматив-хокукый актларның, шулай ук җирле үзидарә органнары хокукый актларының гамәли көче инвесторларга кагылмый.

20 статья. **Килешүнең үтәлешен тикшереп тору**

1. Килешүнең үтәлешен дәүләт тарафыннан тикшереп торуны үз компетенцияләре нигезендә дәүләт хакимияте органнары башкара.

2. Килешүнең үтәлешен тикшереп торучы дәүләт органнарының әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле вәкилләре фәкать килешүнең үтәлешен тикшереп тору вазыйфаларын башкару максатларында гына килешү буенча эш башкару объектларына тоткарлыксыз үтеп керергә, шулай ук әлеге эшләрне башкаруга кагылышлы документлар-

дан файдаланырга хокуклы.

21 статья. **Якларның килешү буенча җаваплылыгы**

1. Яклар килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, граждан законнарын үтәгән килеш, килешү шартлары нигезендә җаваплы булалар.

2. Дәүләт килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта зыяннарны түләү турында инвестор таләпләрен канәгатьләндерү өчен Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе арасында чыгымнарны бүлешү шартлары һәм тәртибе, шулай ук дәүләткә куелган дәүләтнең килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәвенә кагылышлы таләбен караганда Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башкарма хакимияте органнарының үзара мөнәсәбәте тәртибе әлеге Законның 11 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән шартнамәләр белән билгеләнә. Килеп чыгучы каршылыклар «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы хакимияте органнары арасында эшләрне чикләү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсен һәм тиешле килешүләрне исәпкә алып хәл ителә.

22 статья. **Килешүнең гамәлдә булуын туктату**

Килешүнең гамәлдә булуы аның гамәли вакыты беткәч туктатыла яисә якларның килешүе буенча вакытыннан алда туктатыла, шулай ук килешүдә каралган тәртиптә башка нигезләрдә килешүгә кул куелган көндә гамәлдә булган законнар нигезендә туктатыла.

Яклар килешүе буенча килешүнең гамәлдә булуын туктату, конкурс уздырудан гайре, башлангыч килешү өчен каралган тәртиптә үк башкарыла.

23 статья. **Бәхәсләрне хәл итү**

Дәүләт һәм инвестор арасындагы килешүне үтәүгә, туктатуга һәм аны гамәлгә яраксыз дип тануга бәйле бәхәсләр килешү шартлары нигезендә судта, арбитраж судта яисә арадашчы судта (шул исәптән халыкара арбитраж институтларында) хәл ителә.

24 статья. **Дәүләт иммунитеты**

Чит ил гражданнары һәм чит ил юридик затлары белән төзелүче килешүләрдә законнар нигезендә дәүләтнең суд иммунитетыннан дәгъваны алдан тәэмин итүгә һәм суд һәм

(яисә) арбитраж карарын үтәүгә карата иммунитеттан баш тартуы каралырга мөмкин.

## III БҮЛЕК. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

25 статья. **Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре**

Татарстан Республикасы халыкара шартнамәләре белән әлеге Законда каралганнан үзгә кагыйдәләр билгеләнсә, халыкара шартнамәләре кагыйдәләре кулланыла.

26 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе турында**

Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

а) әлеге Закон нигезендә продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган җир асты кишәрлекләре хакындагы тәкъдимнәрне, шулай ук әлеге Законны кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы каравына кертергә тиеш;

б) үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2146

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 591. Сатудан салым турында

Әлеге Закон белән "Россия Федерациясендә салым системасы нигезләре турында" Россия Федерациясе Законының 20 статьясына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә сатудан салым билгеләнә һәм кертелә.

1 статья. **Салым түләүчеләр**

Сатудан салым түләүчеләргә (алга таба - салым түләүчеләр) түбәндәгеләр керә:

законнар нигезендә төзелгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан юридик затлар, аларның филиаллары, вәкиллекләре һәм башка аерымланган бүлекчәләре;

чит илләрнең законнары нигезендә төзелгән, гражданлык хокукына ия чит ил юридик затлары, компанияләр һәм башка корпоратив төзелмәләр, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан халыкара оешмалар, аларның филиаллары һәм вәкиллекләре (алга таба - чит ил оешмалары);

индивидуаль эшкуарлар - юридик зат булмыйча гына эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, товарларны мөстәкыйль сатучы (эш башкаручы һәм хезмәт күрсәтүче) физик затлар.

2 статья. **Салым салу объекты**

Акчалата исәп-хисап нигезендә ваклап яисә күпләп сатыла торган товарларның (эш башкаруларның, хезмәт күрсәтүләрнең) хакы сатудан салым буенча салым салу объекты булып таныла.

2. "Россия Федерациясендә салым системасы нигезләре турында" Россия Федерациясе Законының 20 статьясына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Федераль закон нигезендә түбәндәге товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) хакы сатудан салым буенча салым салу объекты була алмый;

икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре, сөт һәм сөт продуктлары, үсемлек майлары, маргарин, ярмалар, шикәр, тоз, бәрәңге, балалар туклануы һәм диабетик туклану продуктлары;

балаларның өс киеме һәм аяк киеме;

дарулар, протез-ортопедия әйберләре;

торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр, шулай ук халыкка дәүләт яисә муниципаль торак биналарны наемга тапшыру, тулай торакларда тору урыннары бирү буенча хезмәт күрсәтүләр;

театр-тамаша, мәдәни-агарту гамәлләре үткәргәндә дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең һәм мәдәният, сәнгать оешмаларының (театрларның, кинотеатрларның, концерт оешмаларының һәм коллективларының, клуб учреждениеләренең, китапханәләрнең, циркларның, лекторийларның, планетарийларның, культура һәм ял паркларының, ботаника бакчаларының, зоопаркларның) мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә хезмәт күрсәтүләре;

күчемсез мөлкәткә караучы биналар, корылмалар, җир кишәрлекләре һәм башка төрле объектлар, кыйммәтле кәгазьләр;

мәктәпкәчә учреждениеләрдә балаларны тоту һәм авыруларны, өлкәннәрне карау буенча хезмәт күрсәтүләр;

муниципаль берәмлекләрнең гомуми файдаланыштагы транспортында пассажирлар йөртү (таксидан гайре), шулай ук шәһәр яны тирәсендә елга, тимер юлы һәм автомобиль транспортында пассажирлар йөртү буенча хезмәт күрсәтүләр;

кредит оешмалары, иминләштерүчеләр, дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары, кыйммәтле кәгазьләр базарында профессиональ катнашучылар тарафыннан үз эшчәнлекләре кысаларында күрсәтелүче һәм лицензияләнергә тиешле хезмәт күрсәтүләр, шулай ук адвокатлар коллегиясе күрсәтә торган хезмәтләр;

күмү бюролары, зиратлар һәм крематорийларның ритуаль хезмәт күрсәтүләре, дини оешмаларның йолаларны һәм тантаналарны үтәү хезмәтләре;

дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче тиешле пошлиналар һәм җыемнар алына торган хезмәтләр;

уку-укыту, өйрәнү-җитештерү, фәнни яисә тәрбияви процесска бәйле һәм дәүләт, муниципаль мәгариф учреждениеләре җитештерә торган товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр);

инвалидлар өчен шифаханә-курорт һәм савыктыру учреждениеләре, ял итү учреждениеләре юлламалары (курсовкалары).

Татарстан Республикасы территориясендә халыкның аз керемле катламының көнкүреш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау максатларында түбәндәгеләрнең хакына салым салынмый:

ит (кош итен дә кертеп);

атланмай;

йомырка;

чәй;

шырпы;

медицина әйберләре;

һава юлларының җирле линияләрендә пассажирларны ташу буенча хезмәт күрсәтүләр;

оешмаларның һәйкәлләр, кабер ташлары һәм чардуганнар эшләү буенча хезмәт күрсәтүләре;

мәктәп һәм студентлар ашханәләрендә туклану;

Татарстан Республикасының шифаханә-курорт һәм савыктыру учреждениеләренә юлламалар (курсовкалар);

Бөек Ватан сугышы инвалидларына, анда катнашучыларга һәм аларга тиңләштерелгән гражданнарга ведомстводан тыш саклау хезмәтләре күрсәтү;

көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган газ һәм халыкка сатыла торган каты ягулык (утын, күмер);

мунчаларның гомуми бүлекләрендә юыну.

Татарстан Республикасы территориясендә хакы сатудан салым салынудан азат ителүче товарлар, эш башкарулар һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеге буенча аңлатмалар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

3. Әлеге Закон максатларында акчалата исәп-хисап нигезендә сату кредит һәм башка хисап-түләү документлары ярдәмендә банкларның исәп-хисап чеклары буенча, халыкны социаль яклау чеклары буенча, физик затларның җаваплылык йөкләмәләре буенча, банклардагы счетлардан акча күчерү буенча исәп-хисап ясап сату, шулай ук халыкка товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) башка товарларга (эш башкаруларга, хезмәт күрсәтүләргә) алмашуга тиңләштерелә.

3 статья. **Сатудан салым базасы**

Сатудан салымны исәпләү өчен салым базасын билгеләгәндә товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) хакына өстәлгән бәяләргә салым һәм акциз алынырга тиешле товарлар өчен акцизлар керә.

4 статья. **Салым ставкасы**

Сатудан салым ставкасы түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

алкоголь продукциясе буенча - 5 процент;

калган товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) буенча - 3 процент, әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пункты нигезендә азат ителгән товарлар моңа керми.

5 статья. **Салымны исәпләү һәм түләү тәртибе**

1. Республика территориясендә урнашкан филиаллары, вәкиллекләре һәм эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра торган башка урыннары булган оешмалар сатудан салымны филиаллар, вәкиллекләр, эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра торган башка урыннар урнашкан җирдә түлиләр.

Филиаллары, вәкиллекләре һәм эшчәнлекләрен гамәлгә

ашыра торган башка урыннары булган оешмалар салым түләүче сыйфатында салым органында үзе урнашкан җирдә дә, һәр филиалы, вәкиллеге һәм эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка урында да, шулай ук үз карамагындагы күчемсез мөлкәт һәм транспорт чаралары булган урында да теркәлергә тиешләр.

Бу Закон максатларында "эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка урын" дигәндә, мөстәкыйль балансы һәм исәп-хисап счеты булган оешма бүлекчәләре, шулай ук мөстәкыйль балансы һәм аерым исәп-хисап счеты булмаган, аларны төзегән юридик затларның гамәлгә кую документларында күрсәтелгән (күрсәтелмәгән), шулай ук баш предприятиене теркәү урыныннан читтә күчемсез мөлкәте һәм транспорт чаралары булган оешма бүлекчәләре аңлашыла.

Индивидуаль эшкуарлар сатудан салымны яшәү урыннарында, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыннарында, күчемсез мөлкәт яки транспорт чаралары булган урыннарда түлиләр.

Индивидуаль эшкуарлар үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра торган һәр урында салым түләүче сыйфатында теркәлергә тиешләр.

Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, әмма эшкуарлык эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар республикада эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында салым түләүчеләр исәбенә кертелергә тиешләр.

2. Товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) сатканда, салым түләүче салым суммасын әлеге товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алучыга (заказчыга) түләргә тәкъдим иткән товар хакына кертә.

Күрсәтелгән сумма салым түләүче тарафыннан товар бәясенең тиешле салым ставкасына туры килгән сатудан салым исәпкә алынмаган процентлардагы өлеше буларак билгеләнә һәм сатып алучыга (заказчыга) түләүгә тәкъдим ителгән товар хакына кертелә.

Сатудан салым суммасы касса һәм товар чекларында аерым юл белән билгеләнми.

Салым түләүче бу Законның 2 статьясындагы 1 нче пунктында санап кителгән төрле ставкалар буенча салым салынырга тиешле товарларны, шулай ук бу Законның 2

статьясындагы 2 нче пункты буенча сатудан салым салынмый торган товарларны реализацияләүнең аерым исәбен алып барырга тиеш.

4. Товарларның (эш башкаруларның, хезмәт күрсәтүләрнең) аерым исәбе алып барылмаган очракта, салым түләүче сатудан салымны товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) максималь ставка буенча реализацияләүнең гомуми суммасыннан исәпли.

5. Сатудан салым исәпләү максатларында товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) реализацияләүне аерым исәптә тоту методикасын Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясе белән берлектә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы эшли.

6. Товарны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алганда түләнгән сатудан салым суммасы капланмый, бары тик сатып алучы тарафыннан сатып алынган товарларның (эш башкаруларның, хезмәт күрсәтүләрнең) бәясе составында исәпкә генә алына.

7. Сатудан салым түләүче оешмалар, оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, сатудан салымны бюджетка тулысынча кертү максатларында, түләү вакыты җиткәнчегә кадәр банк учреждениеләренә бюджетка салым суммасын күчерү буенча түләү йөкләмәсен бирергә тиешләр.

8. Индивидуаль эшкуарлар тарафыннан хисап чорында тупланган җыелма керем, исәпләнгән салым суммасы кысаларында, сатудан чынлыкта түләнгән салым суммасы кадәр киметелә.

9. Салым түләүчеләр тарафыннан түләнергә тиешле сатудан салым суммасы һәр хисап чоры йомгаклары буенча ел башыннан алып үсә барган, әлеге вакыт эчендә салым салынырга тиешле акча әйләнешенең салым ставкасына тапкырлануы нәтиҗәсе буларак билгеләнә.

Салым түләүче салымны исәпләү һәм түләү буенча исәп-хисапларны салым органына 1 нче кушымтада күрсәтелгән рәвештә түбәндәге вакытларда кертә:

юридик затлар - хисап аеннан соң килүче айның 20 сендә;

индивидуаль эшкуарлар - кварталның икенче аеның 5 ендә.

10. Сатудан салым буенча түләүләр суммасының 40 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына, 60 проценты җирле бюджетларга кертелә.

6 статья. **Салым түләү вакыты**

1. Оешмалар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә исәпләнгән сатудан салым суммасы һәр ун көн саен - хисап аеннан соң килгән айның 11, 21 һәм 1 числосында соңгы ай буенча бюджетка түләнергә тиешле салым суммасының өчтән бер өлеше күләмендә, хисап аеннан соң килгән айның 20 сенә кабат исәп-хисап ясап, узган вакыт эчендә реализация буенча факттагы әйләнештән чыгып түләнә.

2. Индивидуаль эшкуарлар салымны квартал саен, товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) реализацияләүдән кергән акчаның фактта әйләнештә йөрүеннән чыгып, хисап кварталыннан соң килүче икенче айның 5 еннән дә соңга калмыйча түлиләр.

7 статья. **Салым түләүченең җаваплылыгы, сатудан салым кертүне тикшереп тору**

1. Салымны дөрес исәпләү һәм үз вакытында түләү җаваплылыгы салым түләүчегә һәм аларның урындагы затларына йөкләнә.

Әлеге Законны үтәмәгән өчен салым түләүче законнар нигезендә җаваплы була.

Сатудан салым кертүне тикшереп тору салым законнары нигезендә салым органнары тарафыннан башкарыла.

8 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе турында**

1. Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы территориясендә әлеге Закон гамәлгә кергән көннән башлап «Россия Федерациясендә салым системасы нигезләре турында» Россия Федерациясе Законының 20 статьясындагы 1 пунктының «г» пунктчасында, шулай ук 21 статьясындагы 1 пунктының «г», «е», «и», «к», «л», «м», «н», «о», «п», «р», «с», «т», «у», «ф», «х», «ц» пунктчаларында каралган салымнар салынмый.

2. Татарстан Республикасы Президентына үз норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштыруны тәкъдим итәргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына

үз норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштыруны йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 27 мае
№ 2194

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 592. Хәйрия эшчәнлеге турында

Әлеге Закон хәйрия эшчәнлеген хокукый җайга салу нигезләрен урнаштыра, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан аңа ярдәм итүнең мөмкин булган рәвешләрен билгели, Татарстан Республикасында хәйрия эшчәнлеген киң тарату һәм үстерү максатларында хәйрия оешмаларын төзү һәм аларның эшчәнлеге үзенчәлекләрен билгели.

#### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Хәйрия эшчәнлеге**

Әлеге Закон максатлары өчен хәйрия эшчәнлеге дигәндә, гражданнарга яисә юридик затларга мөлкәтне, шул исәптән акчаларны, интеллектуаль милек объектларын риясыз (кире кайтарусыз яки ташламалы шартларда) бирү, риясыз эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү, башкача ярдәм күрсәтү буенча физик һәм юридик затларның ихтыярый эшчәнлеге күздә тотыла.

2 статья. **Хәйрия эшчәнлегенең максатлары**

Хәйрия эшчәнлеге социаль әһәмиятле бурычларны хәл итү максатларында башкарыла, шул исәптән:

аз керемле гражданнарга, шул исәптән инвалидларга, өлкән яшьтәге затларга, күп балалы гаиләләргә, ата-аналары тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, үзләренең физик яисә интеллектуаль үзенчәлекләре яисә башка сәбәпләр аркасында үз ихтыяҗларын мөстәкыйль тәэмин итәргә, үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашырырга сәләтле булмаган башка затларга социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау;

ветераннарның һәм инвалидларның иҗтимагый

оешмаларына социаль ярдәм итү;

табигый бәла-казалар һәм һәлакәтләр, социаль, милли, дини конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күргәннәргә, репрессия корбаннарына, качакларга һәм мәҗбүри күченүчеләргә ярдәм күрсәтү;

халыклар арасында тынычлыкны, дуслыкны һәм татулыкны ныгытуга ярдәм итү;

җәмгыятьтә гаилә абруен һәм ролен ныгытуга ярдәм күрсәтү;

мәгариф, фән, мәдәният, сәнгать, мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеккә, шәхеснең рухи үсешенә ярдәм итү;

гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлеккә, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, гражданнарның әхлакый-психологик халәтен яхшыртуга ярдәм итү;

физкультура һәм массакүләм спорт өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү;

әйләнә-тирә табигать мохитен саклау;

тарихи, культ, мәдәни әһәмияткә, табигатьне саклау әһәмиятенә ия объектларны, күмү урыннарын саклау һәм тиешенчә тоту, шулай ук дини объектларны һәм берләшмәләрне төзү, торгызу һәм аларның тиешле эшчәнлеген тәэмин итү;

аналарны, балаларны, аталарны яклауга ярдәм күрсәтү.

Коммерция оешмаларына акча һәм башка матди чаралар җибәрү, бүтән рәвешләрдә ярдәм күрсәтү, шулай ук сәяси фиркаләргә, хәрәкәтләргә, төркемнәргә һәм компанияләргә ярдәм итү хәйрия эшчәнлегенә керми.

3 статья. **Хәйрия эшчәнлеген хокукый җайга салу**

Хәйрия эшчәнлеген хокукый җайга салу әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актлары, шулай ук халыкара шартнамәләр белән гамәлгә ашырыла.

Хәйрия эшчәнлеген җайга салучы, әмма башка норматив-хокукый актлардагы нормалар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган федераль законнарга, халыкара хокукый актларга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм әлеге Законга каршы килмәскә тиеш.

4 статья. **Хәйрия эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы**

Физик һәм юридик затлар хәйрия эшчәнлеген ихты-

ярыйлык нигезендә, индивидуаль рәвештә яисә берләшеп, хәйрия оешмасы оештырып яки оештырмыйча һәм хәйрия эшчәнлеге максатларын ирекле сайлау нигезендә законнарга таянып, тоткарлыксыз гамәлгә ашырырга хокуклы.

5 статья. **Хәйрия эшчәнлегендә катнашучылар**

Әлеге Закон максатлары өчен хәйрия эшчәнлегендә катнашучылар дигәндә, хәйрия эшчәнлеген закон нигезендә гамәлгә ашыручы (шул исәптән гамәлдәге хәйрия оешмасына ярдәм итү яисә яңасын оештыру юлы белән) физик һәм юридик затлар, шулай ук мәнфәгатьләре кайгыртылып хәйрия эшчәнлеге гамәлгә ашырылучы физик һәм юридик затлар: хәйриячеләр, ихтыярый ярдәм күрсәтүчеләр, хәйрия алучылар күздә тотыла.

Хәйриячеләр - хәйрия иганәләрен түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашыручы затлар:

мөлкәтне, шул исәптән акчаларны, кыйммәтле кәгазьләрне һәм интеллектуаль милек объектларын түләүсез яисә өстенлекле ташламалар шартларында милек итеп тапшыру;

теләсә нинди милек хокукы объектларын биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукларын түләүсез яисә өстенлекле ташламалар шартларында бирү;

иганәчеләр - юридик затлар тарафыннан түләүсез яисә өстенлекле ташламалар шартларында эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү.

Хәйриячеләр үз иганәләренең максатларын һәм алардан файдалану тәртибен билгеләргә хокуклы.

Ихтыярый ярдәм күрсәтүчеләр - хәйрия эшчәнлеген түләүсез хезмәт рәвешендә хәйрия алучы мәнфәгатьләрендә, шул исәптән хәйрия оешмасы мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашыручы физик затлар. Хәйрия оешмасы ихтыярый ярдәм күрсәтүчеләрнең бу оешмадагы эшчәнлегенә бәйле чыгымнарын (командировка, транспорт чыгымнарын һәм башкаларны) түли ала.

Хәйрия алучылар - хәйриячеләрдән хәйрия иганәләре алучы, ихтыярый ярдәм күрсәтүчеләрдән ярдәм алучы физик һәм юридик затлар.

6 статья. **Хәйрия оешмасы**

Хәйрия оешмасы - җәмгыять яисә аның аерым категория гражданнары мәнфәгатьләрендә әлеге Законда каралган максатларны хәйрия эшчәнлеген башкару юлы белән гамәлгә

ашыру өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешма ул.

Хәйрия оешмасының керемнәре аның чыгымнарыннан артып киткәндә, артык сумма аның гамәлгә куючылары (әгъзалары) арасында бүленергә тиеш түгел, ул хәйрия оешмасы нинди максатларда төзелгән булса, шул максатларны гамәлгә ашыруга юнәлтелә.

7 статья. **Хәйрия оешмаларының рәвешләре**

Хәйрия оешмалары җәмәгать оешмалары (берләшмәләре), фондлар рәвешендә һәм хәйрия оешмалары өчен законнарда каралган башка оештыру-хокукый рәвешләрдә төзелә алалар.

8 статья. **Хәйрия оешмасын гамәлгә куючылар**

Хәйрия оешмасының рәвешенә карап, физик һәм (яисә) юридик затлар аны гамәлгә куючылар була алалар.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, дәүләт унитар предприятиеләре, дәүләт учреждениеләре, шулай ук җирле үзидарә органнары, әгәр законнарда башкача каралмаган булса, хәйрия оешмасының гамәлгә куючылары була алмыйлар.

9 статья. **Хәйрия оешмасын дәүләт теркәвенә алу**

Хәйрия оешмасы дәүләт теркәвенә алынган мизгелдән юридик зат хокукына ия була.

Хәйрия оешмасын дәүләт теркәвенә алу законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Хәйрия оешмасын дәүләт теркәвенә алудан баш тарту**

Хәйрия оешмасын төзүнең билгеләнгән тәртибен бозу яисә аның гамәлгә кую документларының законнар таләпләренә туры килмәве аны дәүләт теркәвенә алудан баш тартуга китерә.

Хәйрия оешмасына гражданның яшәү урыны буенча граждан тарафыннан юридик адрес бирелү аркасында, хәйрия оешмасын төзүнең максатка яраксызлыгы аркасында, шулай ук бер үк территориядә ике һәм аннан да күбрәк шундый ук хәйрия оешмасы булу аркасында аны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту рөхсәт ителми.

Теркәүче органның хәйрия оешмасын дәүләт теркәвенә алудан баш тартуы турындагы карарына, шулай ук аның мондый теркәүдән тайпылуына карата суд тәртибендә шикаять

белдерелергә мөмкин.

**11 статья. Хәйрия эшчәнлегендә катнашучыларга салым ташламалары**

Хәйрия эшчәнлегендә катнашучыларга законнар нигезендә салым ташламалары бирелә.

**12 статья. Хәйрия оешмасына идарә итү**

Хәйрия оешмасына идарә итү хәйрия оешмасы уставында каралган тәртиптә коллегиаль орган тарафыннан башкарыла.

Хәйрия оешмасы уставында каралган тәртиптә төзелүче коллегиаль орган хәйрия оешмасы идарәсенең иң югары органы була.

Хәйрия оешмасының иң югары идарә органы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

хәйрия оешмасының уставын үзгәртү;

хәйрия оешмасының башкарма органнарын, аның контроль-ревизия органнарын оештыру һәм аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

хәйрия программаларын раслау;

хәйрия оешмасының еллык планын, бюджетын һәм аның еллык хисабын раслау;

коммерциячел булмаган оешмалар төзү турында, хуҗалык җәмгыятьләрендә һәм ышанычка нигезләнгән ширкәтләрдә акча кертүче буларак катнашу, филиаллар һәм вәкиллекләр ачу турында карарлар кабул итү;

хәйрия оешмасын (хәйрия фондыннан тыш) үзгәртеп кору яисә бетерү турында карарлар кабул итү.

Хәйрия оешмасының иң югары идарә органы әгъзалары бу органда үз вазыйфаларын түләүсез башкаралар. Хәйрия оешмасының иң югары идарә органы составында аның башкарма органнарыннан бер генә хезмәткәр (хәлиткеч тавыш хокукы белән йә ансыз гына ) булырга мөмкин.

Хәйрия оешмасының иң югары идарә органы әгъзалары һәм хәйрия оешмасының урындагы затлары гамәлгә куючысы (катнашучысы) шушы хәйрия оешмасы булган коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларның администрацияләрендә штатлы урынны биләргә хокуклы түгел.

**13 статья. Хәйрия оешмасын үзгәртеп кору яисә бетерү**

Хәйрия оешмасын үзгәртеп кору яисә бетерү законда

билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Хәйрия оешмасы хуҗалык ширкәте яисә җәмгыяте итеп үзгәртелә алмый.

Хәйрия оешмасын бетергәндә, аның кредитор таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган мөлкәте уставта каралган тәртиптә яисә, әгәр хәйрия оешмасының мөлкәтеннән файдалану тәртибе аның уставында каралмаган булса, бетерү комиссиясе карары белән хәйрия максатларында файдаланыла.

14 статья. **Хәйрия оешмасының эшчәнлеге**

Хәйрия оешмасы, нинди максатлар өчен төзелгән булса, шул максатларга ирешүгә юнәлдерелгән хәйрия эшчәнлеген әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы.

Хәйрия оешмасы ресурслар җәлеп итү һәм реализацияләүгә бәйле булмаган эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы.

Хәйрия оешмасы, нинди максатлар өчен төзелгән булса, бары тик шул максатларга ирешү өчен генә һәм шул максатларга туры килерлек кенә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырырга хокуклы.

Хәйрия максатларын тормышка ашыруның матди шартларын булдыру өчен хәйрия оешмасы хуҗалык җәмгыятьләрен гамәлгә куярга хокуклы. Хуҗалык җәмгыятьләрендә хәйрия оешмасының башка затлар белән бергәләп катнашуы законнар нигезендә рөхсәт ителми.

15 статья. **Хәйрия оешмасының филиаллары һәм вәкиллекләре**

Хәйрия оешмасы, законнар таләпләрен бозмыйча, үзенең филиалларын төзергә һәм вәкиллекләрен ачарга хокуклы.

Әгәр Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрендә башкача каралмаган булса, чит дәүләтләр территорияләрендә хәйрия оешмалары тарафыннан филиаллар төзү һәм вәкиллекләр ачу шул дәүләтләрнең законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Филиаллар һәм вәкиллекләр юридик затлар булмыйлар, аларны төзегән хәйрия оешмасының мөлкәтеннән файдаланалар һәм ул раслаган нигезләмәләргә таянып эш итәләр. Филиалларның һәм вәкиллекләрнең мөлкәте аларның аерым балансында һәм аларны төзегән хәйрия оешмасы балансында исәпкә алына.

Филиалларның һәм вәкиллекләрнең җитәкчеләре хәйрия оешмасының иң югары идарә органы тарафыннан билгеләнәләр һәм алар хәйрия оешмасы тарафыннан бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итәләр.

Филиаллар һәм вәкиллекләр аларны төзегән хәйрия оешмасы исеменнән эшчәнлек алып баралар. Филиалларның һәм вәкиллекләрнең эшчәнлеге өчен аларны төзегән хәйрия оешмасы җаваплы була.

16 статья. **Хәйрия оешмаларының берләшмәләре (ассоциацияләре һәм берлекләре)**

Хәйрия оешмалары үзләренең устав максатларын гамәлгә ашыру мөмкинлекләрен киңәйтү өчен шартнамәчел нигездә төзелүче ассоциацияләргә һәм берлекләргә берләшә алалар.

Хәйрия оешмаларының берләшмәләрен (ассоциацияләрен һәм берлекләрен) оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе законнар белән билгеләнә.

17 статья. **Хәйрия оешмасының мөлкәтен формалаштыру чыганаклары**

Хәйрия оешмасының мөлкәтен формалаштыру чыганаклары түбәндәгеләр була:

хәйрия оешмасын гамәлгә куючыларның кертемнәре;

әгъзалардан керүче кертемнәр (әгъзалыкка нигезләнгән хәйрия оешмалары өчен);

гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан акчалата яисә натуралата кертелә торган хәйрия иганәләре, шул исәптән максатчыл характердагы иганәләр (хәйрия грантлары);

реализацияләүгә бәйле булмаган гамәлләрдән керемнәр, кыйммәтле кәгазьләрдән керемнәр дә шуңа керә;

ресурсларны җәлеп итү эшчәнлегеннән керемнәр (законнар нигезендә хәйриячеләрне һәм ихтыярый ярдәм күрсәтүчеләрне җәлеп итү кампанияләрен уздыру, күңел ачу, мәдәни, спорт гамәлләрен һәм массакүләм башка гамәлләрне оештыру, хәйрия иганәләрен җыю кампанияләрен уздыру, лотереялар һәм аукционнар уздыру да, иганәчеләрдән алынучы мөлкәтне һәм иганәләрне аларның теләкләре белән сату да шунда керә);

законнарда рөхсәт ителгән эшкуарлык эшчәнлегеннән керемнәр;

федераль бюджеттан, Татарстан Республикасының республика бюджетыннан, җирле бюджетлардан һәм бюджеттан тыш фондлардан керемнәр;

хәйрия оешмасы гамәлгә куйган хуҗалык җәмгыятьләре эшчәнлегеннән керемнәр;

ихтыярый иганәчеләр хезмәте;

законда тыелмаган башка чыганаклар.

18 статья. **Хәйрия оешмасының мөлкәте**

Әгәр законнарда башкача каралмаган булса, биналар, корылмалар, җиһазлар, акча, кыйммәтле кәгазьләр, мәгълүмат ресурслары, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре, башка мөлкәт хәйрия оешмасы милкендә яисә аның бүтән әйбер хокукында булалар.

Хәйрия оешмасы үз милкендәге һәм әйбер хокукындагы мөлкәткә карата законнарга, бу оешманың уставына, хәйрияче теләкләренә каршы килми торган теләсә нинди алыш-биреш гамәлләрен законнар нигезендә кылырга хокуклы.

Хәйрия оешмасының административ-идарә персоналына хезмәт хакы түләү өчен финанс елында үзе тота торган финанс чараларының 20 процентыннан да артыгын кулланырга хокукы юк. Әлеге чикләү хәйрия программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы затларның хезмәте өчен түләүгә кагылмый.

Әгәр хәйрияче тарафыннан яисә хәйрия программасында башкача билгеләнмәгән булса, акчалата кергән хәйрия иганәләренең кимендә 80 проценты хәйрия оешмасы тарафыннан бу иганә алынган мизгелдән ел дәвамында хәйрия максатлары өчен кулланылырга тиеш. Әгәр хәйрияче тарафыннан яисә хәйрия программасында башкача билгеләнмәгән булса, натуралата алынган хәйрия иганәләре алар алынган мизгелдән ел дәвамында хәйрия максатларына җибәрелә.

Хәйрия оешмасының мөлкәте (сату, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү рәвешләрендә һәм башка рәвешләрдә) бу оешманың гамәлгә куючыларына (әгъзаларына) башка затларга караганда файдалырак шартларда тапшырылмый.

Хәйрия оешмасы счетына кергән бюджет акчалары тулысынча аларны бүлгәндә күрсәтелгән хәйрия максатларында файдаланыла.

19 статья. **Хәйрия программасы**

Хәйрия программасы хәйрия оешмасының иң югары

идарә органы тарафыннан расланган һәм бу оешманың тиешле устав максатларына туры килә торган конкрет бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән гамәлләр комплексыннан гыйбарәт.

Хәйрия программасына күздә тотылучы керемнәр һәм планлаштырылучы чыгымнар сметасы (хәйрия программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы затларның хезмәте өчен түләүне дә кертеп) керә, анда гамәлгә ашыруның этаплары һәм вакытлары билгеләнә.

## II БҮЛЕК.
## Хәйрия эшчәнлеге гарантияләре

### 20 статья. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан хәйрия эшчәнлегенә ярдәм итү

Хәйрия эшчәнлегендә һәр катнашучыга хәйрия эшчәнлеген гамәлгә ашырганда тигез хокукларны яклауны һәм закон белән саклanучы мәнфәгатьләрне яклауны тәэмин итү, шулай ук физик һәм юридик затларның хәйрия эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукларына тоткарлык ясаучы урындагы затларның хокукка каршы гамәлләренә карата суд тәртибендә шикаять белдерү хокукы гарантияләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә хәйрия эшчәнлегендә катнашучыларга түбәндәге рәвешләрдә ярдәм итә алалар:

а) законда билгеләнгән тәртиптә салым ташламалары һәм башка өстенлекле ташламалар бирү;

б) хәйрия оешмаларын матди-техник тәэмин итү һәм аларга субсидияләр бирү (дәүләт оешмалары һәм җирле үзидарә органнары оешмалары күрсәтә торган хезмәтләр өчен түләүдән, алар мөлкәтеннән файдаланган өчен түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итүне дә кертеп);

в) хәйрия оешмалары эшләгән хәйрия программаларын конкурс нигезендә финанслау;

г) дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының социаль заказларын конкурс нигезендә урнаштыру;

д) законнарда каралган тәртиптә дәүләт мөлкәтен дәүләттән аеру һәм хосусыйлаштыру барышында аны хәйрия оешмаларына милек итеп түләүсез яисә өстенлекле ташлама

нигезендә тапшыру.

Законнарда билгеләнгән салым ташламалары һәм башка өстенлекле ташламалар хокукына хәйрия оешмалары дәүләт теркәве узган мизгелдән ия булалар.

Хәйрия эшчәнлегенә ярдәм итү, дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм хәйрия оешмаларының үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру максатларында хәйрия эшчәнлегенә ярдәм итү советлары (комитетлары, комиссияләре) төзелергә мөмкин, алар составына дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының, хәйрия оешмаларының, иҗтимагый оешмаларның вәкилләре, җәмәгать эшлеклеләре керә. Бу советлар (комитетлар, комиссияләр) хәйрия эшчәнлегендә катнашучыларга карата хакими вәкаләтләргә ия була алмыйлар, аларның карарлары рекомендация характерында була.

21 статья. **Хәйрия эшчәнлеген тормышка ашыруны тикшереп тору**

Хәйрия оешмасы бухгалтерия исәбен һәм хисабын законнарда билгеләнгән тәртиптә алып бара.

Хәйрия оешмалары эшчәнлегенең төзелү максатларына туры килүен тикшереп тору аларны дәүләт теркәвенә алучы органнарга йөкләнә.

Хәйрия оешмасы салым органнарына ел саен үз эшчәнлеге турында хисап бирә, анда түбәндәге мәгълүматлар була:

- хәйрия оешмасының мөлкәтеннән файдалану һәм хәйрия оешмасы акчаларын тоту буенча әлеге Закон таләпләренең үтәлүен раслаучы финанс-хуҗалык эшчәнлеге турында;
- хәйрия оешмасының иң югары идарә органы персональ составы турында;
- хәйрия оешмасының хәйрия программалары составы һәм эчтәлеге (күрсәтелгән программаларның исемлеге һәм тасвирламасы) турында;
- хәйрия оешмасы эшчәнлегенең асылы һәм нәтиҗәләре турында;
- салым органнары үткәргән тикшерү нәтиҗәләрендә ачыкланган әлеге Закон таләпләрен бозулар һәм аларны бетерү буенча күрелгән чаралар турында.

Теркәү органына еллык хисап финанс-хуҗалык эшчәнлеге

турында салым органнарына бирелүче еллык хисап белән бер үк вакытта бирелә.

Теркәү органы хәйрия оешмаларыннан алынган еллык хисапларның ачыклыгын, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары өчен дә, тәэмин итә.

Хәйрия оешмасы үзенең еллык хисапларының ачыклыгын, массакүләм мәгълүмат чаралары өчен дә, тәэмин итә.

Хәйрия оешмасы эшчәнлеге турында еллык хисапны һәм мәгълүматны бастырып чыгару өчен тотылган акчалар хәйрия максатларына тотылучы чыгымнар буларак исәпләнәләр.

Хәйрия оешмасы керемнәренең күләмнәре һәм структурасы турында мәгълүматлар, шулай ук аның мөлкәте, аның чыгымнары, хезмәткәрләренең саны, аларның хезмәтләре өчен түләү һәм ихтыярый ярдәм күрсәтүчеләрне җәлеп итү турындагы мәгълүматлар законнар нигезендә коммерция сере була алмый.

Салым органнары хәйрия оешмаларының керем чыганакларын, алар алган акчаларның күләмен һәм салымнарның түләнүен законнар нигезендә тикшереп торалар.

Хәйрия оешмасына максатчан билгеләнеш белән үз акчаларын күчерүче хәйриячеләр әлеге акчаларның максатчан файдаланылуы турында аңардан хисап таләп итәргә хокуклы.

22 статья. **Хәйрия оешмасының җаваплылыгы**

Әлеге Закон бозылган очракларда хәйрия оешмасы законнар нигезендә җаваплы була.

Хәйрия оешмасы үз максатларына, шулай ук әлеге Законга каршы килүче гамәлләр кылган очракта, хәйрия оешмасын теркәгән орган аңа язма рәвештә кисәтү җибәрә ала, кисәтүгә карата хәйрия оешмасы тарафыннан суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

Хәйрия оешмасы берничә мәртәбә язма рәвештә кисәтелгән очракта, ул законнарда каралган тәртиптә бетерелергә мөмкин.

Әлеге Законның 14 статьясын бозып башкарылган эшкуарлык эшчәнлегеннән хәйрия оешмасы алган барлык акчалар хәйрия оешмасы урнашкан урынның җирле бюджеты кеременә законнарда билгеләнә торган тәртиптә алып бирелә һәм алар хәйрия максатлары өчен тотылырга тиеш.

Хәйрия оешмалары белән хәйрия максатлары өчен акча күчергән гражданнар һәм юридик затлар арасында әлеге

акчаларны файдалану турындагы бәхәсләр суд тәртибендә карала.

**23 статья. Халыкара хәйрия эшчәнлеген башкару**

Хәйрия эшчәнлегендә катнашучылар законнарда, шулай ук Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрендә билгеләнгән тәртиптә халыкара хәйрия эшчәнлеген башкарырга хокуклы.

Халыкара хәйрия эшчәнлеге халыкара хәйрия проектларында катнашу, халыкара хәйрия оешмалары эшендә катнашу, тиешле хәйрия эшчәнлеге өлкәсендә чит ил партнерлары белән үзара хезмәттәшлек итү юлы белән, шулай ук халыкара практикада кабул ителгән һәм законнарга, халыкара хокук нормаларына һәм принципларына каршы килми торган башка төрле рәвешләрдә башкарыла.

Хәйрия оешмасы чит дәүләтләрнең банк учреждениеләрендә законнар нигезендә счетлар ачарга хокуклы.

Хәйрия оешмасы чит ил гражданнарыннан, гражданлыксыз затлардан, шулай ук чит ил оешмаларыннан һәм халыкара оешмалардан хәйрия иганәләре алырга хокуклы.

Күрсәтелгән иганәләрдән файдалану әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**24 статья. Татарстан Республикасы территориясендә чит ил гражданнарының, гражданлыксыз затларның, чит ил оешмаларының һәм халыкара оешмаларның хәйрия эшчәнлеге**

Чит ил гражданнары, гражданлыксыз затлар, чит ил оешмалары һәм халыкара оешмалар Татарстан Республикасы территориясендә әлеге Закон нигезендә, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре нигезендә хәйрия эшчәнлегендә катнашучылар булырга хокуклы.

**25 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында**

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Әлеге Законның нигезләмәләре ул гамәлгә кергәнче төзелгән хәйрия оешмаларына да кагыла.

Әлеге Закон гамәлгә кергәнче төзелгән хәйрия оешма-

ларының уставлары әлеге Законга каршы килмәгән өлешендә гамәлдә булалар.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2216

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 593. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибенә түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. 21 нче Аксубай административ-территория сайлау округы буенча Татарстан Республикасы халык депутатын сайлаулар нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматы.

2. «Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

3. «Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

4. «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

5. «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. «Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча

Вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. «Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында» Татарстан Республикасы Югары Советы карарына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

9. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

10. Косовога Россия гаскәрләрен кертүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында.

11. Татарстан Республикасы Конституциясенең 86, 153 статьяларының һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешенең үтәлүе турында Татарстан Республикасы Прокуратурасы мәгълүматы.

12. А.П.Гусев кандидатурасын Татарстан Республикасы Дәүләт иминлеге комитеты рәисе урынына килештерү турында.

13. «Татарстан Республикасының Җир кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

14. «Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

15. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе составындагы үзгәрешләр турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

16. Татарстан Республикасының кайбер халык депутатлары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

17. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы составындагы үзгәреш турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2234

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 594. «Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2235

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 595. «Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2236

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 596. «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2237

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 597. «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2238

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 598. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проекты буенча төзәтмәләр 1999 елның 5 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон

чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе, алынган искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, күрсәтелгән закон проектын 1999 елның 5 сентябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карау өчен тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2239

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 599. «Татарстан Республикасының кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасының кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы Законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 5 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе, кертелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, әлеге Закон проектын 1999 елның 5 сентябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карау өчен кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2240

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 600. «Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында» Татарстан Республикасы Югары Советы карарына үзгәрешләр кертү урында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

I. Татарстан Республикасы Югары Советының 1998 елның 10 июлендәге 1727 номерлы «Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында»гы карарына үзгәреш кертү турында» карарының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7) 3 пункты әлеге карар басылып чыккан көннән үз көчен югалткан дип танырга.

II. Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 15 июлендәге 1937-XII номерлы «Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында»гы карарына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, №№ 6-7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 11; 1997, № 121; 1998, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 2 абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

5 пунктта «Татарстан Республикасында торак фондын хосу-сыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булу чорына» сүзләрен «Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында Татарстан Республикасы законын кабул иткәнче» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

6 пунктта «Әлеге Законның гамәлдә булу чорына» сүзләрен «Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында Татарстан Республикасы законын кабул иткәнче» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2241

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 601. «Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2242

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 602. «Косовода, Югославия Союз Республикасы, иминлек урнаштыру буенча халыкара катнашуда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби формированиеләрен файдалану турында» Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы карар кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Белдерүе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Косовода, Югославия Союз Республикасы, иминлек урнаштыру буенча халыкара катнашуда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби формированиеләрен файдалану

турында» Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы карар кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Белдерүенең текстын кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге Белдерүен Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советына һәм Дәүләт Думасына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарына, Татарстан Республикасының чит ил вәкиллекләренә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2243

## «Косовода, Югославия Союз Республикасы, иминлек урнаштыру буенча халыкара катнашуда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби формированиеләрен файдалану турында» Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы карар кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

## БЕЛДЕРҮЕ

«Косовода, Югославия Союз Республикасы, иминлек урнаштыру буенча халыкара катнашуда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби формированиеләрен файдалану турында» Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы карар кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тирән борчылуын һәм кайгыртуын белдерә.

Татарстан Республикасы парламенты Югославия территориясендә хәрби сәяси конфликт башланганнан бирле принципиаль позициядә тора. Бу позиция Дәүләт Советының 1999 елның 8 апрелендәге Белдерүендә чагылыш тапты. Тормыш этникара һәм конфиссияара конфликтларны илләр һәм халыклар арасындагы үзара ихтирамга корылган мөнә-

сәбәтләр нигезендә, бары тик сәяси чаралар белән генә хәл итүнең дөреслеген раслады.

Россиядәге гаять катлаулы сәяси вәзгыятьләрне җайга салу буенча Татарстан Республикасы инициативалары этник азчылыкларның хокукларын һәм ирекләрен яклауның тынычлыкны һәм җәмгыятьтәге социаль тотрыклылыкны ныгытуның иң мөһим шарты булуын раслый.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Россия Федерациясендәге аеруча тирән социаль-икътисадый кризис шартларында, бәяләр туктаусыз арта барганда, хезмәт хаклары һәм социаль түләүләр даими рәвештә тоткарланганда, җәмгыятьнең физик һәм рухи сәламәтлеге какшаганда, безнең ватандашларыбыз - күп кенә төбәкләрнең халкы цивилизациянең иң кирәкле уңайлыкларыннан мәхрүм ителгән бер заманда болай да җитәр-җитмәс финанс ресурсларын тынычлык урнаштыру операциясендә Россия контингентын катнаштыруга тотуны мәгънәсезлек, дип саный.

Бүген, Россия Федерациясенең үзендә - Кавказда күптән көтелгән тынычлык һәм татулык булмаган килеш, Ичкерия Чечня Республикасы хәрабәләр эчендә ятканда, ә меңләгән качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр сыеныр урын һәм яшәү чыганагы эзләп Россия буйлап каңгырап йөргәндә, үз дәүләтеңнең язмышы турында онытып, тынычлык урнаштыручылар ролендә булу сәяси әхлаксызлык һәм икейөзлелек.

Косово конфликтында хакимиятнең федераль органнары баштан ук билгән позиция Россия хәрби контингенты катнашуга карата этник албаннарның бер өлешендә тискәре фикер уянуга китерде. Бу, беренче чиратта, болай да куркыныч вәзгыятьне катлауландырырга, Косовода социаль-сәяси киеренкелекнең артуына китерергә мөмкин.

Күп милләтле Татарстан Республикасы гражданнарының гомере өчен җаваплылыкны танып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби формированиеләре составында аларның Косовода катнашуын мөмкин түгел, дип белдерә.

Без Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы әгъзалары - Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевнең һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшинның Югославиягә Россия хәрби контингентын җибәрүдән тыелып калу

кирәклеге турындагы позициясен тулысынча хуплыйбыз.

Сәясәтчеләр Россия Федерациясендәге, шулай ук Косово крае территориясендәге вакыйгаларга карата да килеп чыккан вәзгыятьне тиешенчә бәяләрләр, дип ышанабыз.

Өченче меңьеллык бусагасында бер-береңә ышану һәм тигез хокуклы хезмәттәшлек дәүләтара һәм этникара конфликтларны тыныч юл белән хәл итүнең бердәнбер сәяси чарасы, Җир шарында тотрыклылыкның һәм тынычлыкның нигезе булырга тиеш.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 603. Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитеты рәисе урынына А.П.Гусев кандидатурасын килештерү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитеты рәисе урынына Гусев Александр Петровичны билгеләү турында Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән килешергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2244

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 604. М.Г.Әхмәтовның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

30 нчы Балтач район административ-территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты М.Г.Әхмәтовны Татарстан Республикасы Премьер-министры -

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп билгеләүгә бәйле рәвештә һәм «Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Әхмәтов Марат Готыф улының Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылды дип санарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2245

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 605. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 30 нчы Балтач сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты Әхмәтов Марат Готыф улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы вазыйфаларыннан азат итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 30 мартындагы «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумын төзү турында»гы карарына, алга таба үзгәртүләрне дәвам итеп, түбәндәге сүзләрне өстәргә:

Әхмәтов Марат Готыф улы — 30 нчы Балтач сайлау округы

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2246

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 606. С.А.Когогинның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

14 нче Зеленодол шәһәр административ-территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты С.А.Когогинны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасының икътисад һәм сәнәгать министры итеп билгеләүгә бәйле рәвештә һәм «Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Когогин Сергей Анатольевичның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылды дип санарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2247

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 607. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясе составындагы үзгәрешләр турында

Татарстан Республикасы халык депутаты Л.С.Марков гаризасын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 21 нче Аксубай административ-территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты Леонид Сергеевич Марковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе әгъзасы итеп сайларга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе составы

турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге карарына, алга таба үзгәртүләрне дәвам итеп, аннан соңгы үзгәрешләр белән түбәндәге үзгәрешне һәм өстәмәне кертергә:

- 1 абзацта «15» санын «16» санына алыштырырга;
- 2 абзацта «69 нчы сайлау округы» сүзләреннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Марков Леонид Сергеевич - 21 нче Аксубай административ-территория сайлау округы».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2248

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 608. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 11 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Пленар сессия һәм сессия көн тәртибенә мәсьәләне кертү, төшереп калдыру һәм пленар сессиядә, сессиядә мәсьәләләрне карауның тәкъдим ителгән тәртибен үзгәртү турындагы карарлар, әгәр аның өчен - пленар сессиядә Дәүләт Советының билгеләнгән санлы составының яртысыннан артыграгы йә сессиядә - Дәүләт Советында даими нигездә эшләүче депутатларның яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, һәр мәсьәлә буенча ачык тавыш бирү белән кабул ителәләр».

2. 40 редакцияне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40 статья. Электрон системаны куллануны тикшереп тору өчен пленар сессиядә, көзге һәм язгы сессияләр чорына Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан комиссия төзелә, ул комиссия исә электрон системаны кулланып тавыш бирүне тикшереп тора.

Комиссия әгъзалары тикшереп тору өчен кирәкле барлык мәгълүматны каршылыксыз алырга хокуклы.

Комиссия исемле тавыш бирүнең нәтиҗәләрендәге, чыгыш ясау өчен язылулардагы төгәлсезлекләр, электрон система эшендәге башка ялгышлар турында Татарстан Республикасы халык депутатларының гаризаларын карый һәм аларның нигезлелеген тикшерә».

3. 41 статьяны төшереп калдырырга.

42 статьяны төшереп калдырырга.

5. 46 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«46 статья. Дәүләт Советы Президиумының санлы составы турындагы карар Дәүләт Советы Рәисе тәкъдиме буенча Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителә.

Дәүләт Советы Президиумы составының икедән өчен барлыкка китерелгәннән һәм сайланганнан соң үз вәкаләтләрен башкарырга керешә.

Президиум әгъзаларын сайлау турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының билгеләнгән санлы составының күпчелек тавышы белән һәр кандидатура буенча аерым-аерым кабул ителә».

6. 59 статьяның икенче өлешендә «үткәрелә» сүзе алдыннан «аларның кандидатуралары буенча фикер алышканнан соң» сүзләрен өстәргә.

87 статьяның дүртенче өлешендә «башка» сүзләрен «шул ук яисә башка» сүзләре белән алыштырырга.

8. 104 статьяның икенче өлешен төшереп калдырырга.

9. 105 статьяның беренче өлешендә «түбәндәгеләрне» сүзеннән соң «Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә» сүзләрен өстәргә.

10. 107 статьяда:

беренче өлешенә түбәндәге җөмләне өстәргә: «Закон проектларының зур күләмнәре һәм катлаулылыгы белән бәйле аерым очракларда Дәүләт Советы Рәисе яисә Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары рөхсәте белән күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма ул бер айдан да артмаска тиеш»;

икенче өлешне өченче өлеш дип санарга;

статьяга түбәндәге редакциядә икенче өлеш өстәргә;

«Закон проекты буенча тиешле министрлыкларның, дәүләт комитетларының яисә дәүләт идарәсенең башка

органнарының, прокуратураның, суд органнарының һәм җәмәгать берләшмәләренең фикерләре соратып алынырга мөмкин».

11. 117 статьяда:

беренче өлешнең 2 абзацында «әйтелгән» сүзен төшереп калдырырга, «тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне» сүзләре алдыннан «төзәтмәләр рәвешендәге» сүзләрен өстәргә;

икенче-дүртенче өлешләрне өч-биш өлешләр дип санарга;

статьяга түбәндәге редакциядә икенче өлеш өстәргә:

«Әгәр тавыш бирү йомгаклары буенча закон проектын кабул итү турындагы тәкъдим беренче укылышта тавышларны тиешле санда җыймаса, ул өстәмә тавыш бирүсез генә кире кагылган дип санала. Закон проекты буенча карар Дәүләт Советының тиешле карары белән рәсмиләштерелә;»

бишенче өлешне төшереп калдырырга.

12. 120 статьяның 5 өлешендә «закон проекты» сүзләренә кадәр «комиссия хуплаган һәм кире кагуга тәкъдим иткән төзәтмәләрнең таблицалары белән бергә» дигән сүзләрне өстәргә.

13. 130 статьяда:

дүртенче, бишенче өлешләрне алты, җиде өлешләр дип санарга;

статьяга түбәндәге редакциядә дүртенче өлеш өстәргә:

«Законның аерым нигезләмәләренең килештерелгән редакциясен әзерләү өчен килештерү комиссиясе төзелә, ул комиссия исә законны Дәүләт Советы тарафыннан кабат фикер алышу һәм тавыш бирү өчен Дәүләт Советы Президиумына комиссия төзелгәннән соң ике айдан да соңга калмыйча тәкъдим итә»;

статьяга түбәндәге редакциядә бишенче өлеш өстәргә:

«Килештерү комиссиясенең составы баш даими комиссиянең, Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең, Татарстан Республикасы Президентының Дәүләти-хокукый идарәсе вәкилләреннән һәм закон инициаторларыннан Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан барлыкка китерелә».

14. 131 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«131 статья. Кабул ителгән закон тексты Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең бәяләмәсен алганнан

соң гына Татарстан Республикасы Президентына имза салуга җибәрелә.

Татарстан Республикасы Президенты имза салган һәм кабул ителгән закон тексты закон нигезендә бастырып чыгару өчен Дәүләт Советы Президиумына җибәрелә».

15. 155[1] статьяга түбәндәге редакциядә икенче-дүртенче өлешләрне өстәргә:

«Хөкүмәт сәгате» тематикасы турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Дәүләт Советы Президиумына җибәрелә.

Нотыкчыга мәгълүмат өчен 20 минуттан да артыграк вакыт бирелми. Шуннан соң аңа халык депутатлары сораулар бирергә мөмкин.

Министрлар кабинеты мәгълүматы буенча фикер алышулар ачылмый».

16. XIV бүлекне XV бүлек дип санарга, 159, 160 статьялар 161, 162 статьялар була.

17. Регламентка түбәндәге редакциядә XIV бүлек өстәргә:

«XIV бүлек. Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнарның проектларын карау

159 статья. Дәүләт Советына кергән закон проекты карау һәм тәкъдимнәрне, искәрмәләрне әзерләү өчен Дәүләт Советы Рәисе яисә Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары тарафыннан тиешле даими комиссиягә һәм бәяләү өчен Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрелә.

160 статья. Тиешле даими комиссия, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмәсен исәпкә алып, кирәк чакта закон проекты буенча үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен Дәүләт Советы каравына чыгарырга мөмкин. Тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне карау нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы карар кабул итә, ул карар исә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының закон проекты өчен җаваплы комитетына җибәрелә».

18. XIV бүлек. Йомгак нигезләмәләргә түбәндәге редакциядә 163, 164 статьялар өстәргә:

«163 статья. Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча һәм Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) органнарының закон чыгару

инициативалары мәсьәләләре буенча федераль законнарның кергән проектларын карау әлеге Регламентның XIV бүлегендә каралган процедура буенча гамәлгә ашырыла.

164 статья. Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителмәгән закон проектлары, шулай ук Дәүләт Советы кабул итеп тә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан имзаланмаган законнар яңа чакырылыш Дәүләт Советы тарафыннан әлеге Регламентның XI бүлегендә каралган тәртиптә каралалар».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2249

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 609. Татарстан Республикасы Конституциясенең 86, 153 статьяларының һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешенең үтәлеше турында Татарстан Республикасы Прокуратурасы мәгълүматы хакында

Әлеге мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары В.Г.Метелинның мәгълүматын тыңлап, фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 86, 153 статьяларының һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин

итү өлешенең үтәлеше турында Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары В.Г.Метелинның мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 5 июле
№ 2250

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 610. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 14 июлендәге утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 14 июлендәге утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. «Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

2. «Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

3. «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

4. «Умартачылык турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

5. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында»

Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

9. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10. «Татарстан Республикасы Тукай районының Иске Дөреш җирле үзидарәсенең Яңа Абдул авылын һәм Калмия җирле үзидарәсенең Батрак авылын исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдыру турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

11. «Татарстан Республикасы Тукай районының Әҗмәкәй җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Яңа торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

12. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2265

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 611. «Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законын 1999 елда гамәлгә ашыруның барышы хакында

«Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законын 1999 елда гамәлгә ашыруның барышы хакында» Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын тыңлап, аның буенча фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Күрсәтелгән мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын игътибарга алырга.

2. «Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законының гамәлгә ашырылышы республикада тулы күләмдә алып

барылмавын билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

«Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законын тулы күләмдә гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасында сәламәтлекне саклау системасын камилләштерү гамәлләрен әзерләргә һәм тормышка ашырырга тиеш;

1994 елның ноябренә кадәр «Татарстан Республикасы гражданнарының медицина иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2266

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 612. «Татарстан Республикасы Тукай районының Иске Дөреш җирле үзидарәсенең Яңа Абдул авылын һәм Калмия җирле үзидарәсенең Батрак авылын исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Халкы башка торак пунктларына күчеп китүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Тукай районының Иске Дөреш җирле үзидарәсенең Яңа Абдул авылын һәм Калмия җирле үзидарәсенең Батрак авылын исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2267

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 613. Татарстан Республикасы Тукай районының Әҗмәкәй җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Яңа торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Тукай районының Әҗмәкәй җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән торак пунктын теркәргә, аны исәпкә алу белешмәләренә кертергә һәм аңа Яңа поселогы исемен бирергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2268

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 614. «Умартачылык турында» Татарстан Республикасы Законы хакында

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кире кайтарылган «Умартачылык турында» Татарстан Республикасы Законын караганнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Умартачылык турында» Татарстан Республикасы Законын кабул итүне кичектереп торырга.
2. Күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кабат кертү өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2269

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 615. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 14 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе күрсәтелгән закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 14 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2270

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 616. "Физик культура һәм спорт турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Физик культура һәм спорт турында" Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 14 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының

Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясе әлеге Закон проектын, кертелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 14 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2271

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 617. “Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. “Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында” Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 14 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе әлеге Закон проектын, кертелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 14 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2272

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 618. "Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 14 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе әлеге Закон проектын, кертелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 14 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2273

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 619. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер карарлары үтәлеше вакытын озайту турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үтенечнамәсенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары үтәлеше вакытын 1999 елның 1 августына кадәр озайтырга:

«Казан - Чаллы юлының торышын яхшырту һәм анда травматизмны киметү чаралары турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы хакында» (1999 елның 28 апреле);

«Татарстан Республикасында балаларны гепатитка каршы вакциналаштыру турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматы хакында» (1999 елның 20 мае);

«Татарстан Республикасында көн күрерлек минимум турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан күрелүче чаралар хакында» (1999 елның 16 июне).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2274

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 620. «Казан шәһәрендә йөзмә күпергә автомагистраль төзегәндә табигатьне саклау законнарының үтәлеше турында»гы мәсьәлә буенча мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Казан шәһәрендә йөзмә күпергә автомагистраль төзегәндә табигатьне саклау законнарының үтәлеше турында»гы мәсьәлә буенча Казан шәһәре администрациясе мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2275

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 621. «Мөселманнар өчен балалар тудыру йортлары ачу турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.Г.Шәймәрдановның гарызнамәсе хакында

Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.Г.Шәймәрдановның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Мөселманнар өчен балалар тудыру йортлары ачу турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.Г.Шәймәрдановның гарызнамәсенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2276

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 622. «Су белән тәэмин итү һәм су бирү буенча коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә норматив актларны үтәү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок гарызнамәсе хакында

Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Су белән тәэмин итү һәм су бирү буенча коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә норматив актларның үтәлеше турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколокның гарызнамәсенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2277

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 623. «Халыкны эш белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясын үтәү хакында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок гарызнамәсе турында

Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары А.И.Конюшева мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Халыкны эш белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясын үтәү хакында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок гарызнамәсенә җавапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясенә Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү дәүләт фондының агымдагы елның I яртыеллыгы йомгаклары буенча акчалар тоту эшчәнлеген тикшереп карауны йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 14 июле
№ 2278

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 624. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибенә түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1998 елда Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында һәм 1999 елның I яртыеллыгында Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше

турында хисапны раслау хакында.

«Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

«Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

«Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Мактаулы ана» («Материнская слава») Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Татарстан Республикасының юмалар судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр һәм пикетлар оештыру һәм аларны уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Тузган торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе составындагы үзгәреш турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

«Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый

үсеш һәм реформа мәсьәләләре даими комиссиясе эше турында хисап.

15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе эше турында хисап.

16. «Җир өчен түләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабат карау турында.

17. «Төсле металлар ватыкларын кабул итү, исәпкә алу һәм реализацияләү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2286

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 625. Татар телендәге телерадио тапшыруларны саклау һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелүче чаралар турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татар телендәге телерадио тапшыруларны саклау һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелүче чаралар турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә, татар телендәге тапшырулар өчен аерым канал булдыруны күздә тотып, Татарстан Республикасының телерадио тапшыруларын үстерү буенча республика программасын әзерләүне һәм аны 1999 елның 1 октябренә кадәр кабул итүне тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2287

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 626. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1997 елның 22 маендагы 1174 номерлы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасын үтәүнең барышы хакында»гы карарының 2000 елга кадәр Татар дәүләт милли университетын ачу өлешен үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1997 елның 22 маендагы 1174 номерлы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасын үтәүнең барышы хакында»гы карарының 2000 елга кадәр Татар дәүләт милли университетын ачу өлешен үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматын игътибарга алырга.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты 2000 елда Татар дәүләт милли университетын ачуны тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2288

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 627. 1998 елда Татарстан Республикасының республика бюджеты үтәлеше турындагы хисапны раслау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1998 елда Татарстан Республикасының республика

бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча - 11920822 мең сум күләмендә, чыгымнар буенча 11761302 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан артуын 159520 мең сум күләмендә расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2289

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 628. 1999 елның 6 аенда Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 1999 елның 6 аенда Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты бюджет өлкәсе оешмаларының хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф ставкаларын (окладларын) 1999 елның III кварталында арттыру буенча өстәмә финанс ресурслары эзләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2290

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 629. «Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле

үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре;
1999 елның 21 июле
№ 2291

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 630. «Мактаулы ана» Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Мактаулы ана» Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларын бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2292

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 631. "Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләләр комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2293

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 632. «Татарстан Республикасының юмалар судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының юмалар судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 21 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе әлеге закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 21 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2294

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 633. «Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр, пикетлар оештыру һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр, пикетлар оештыру һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 21 сентябренә кадәр Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе әлеге закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 21 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау

өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2295

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 634. «Искергән торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Искергән торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 21 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясе әлеге закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 21 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2296

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 635. «Төсле металл ватыкларын кабул итү, исәпкә алу һәм реализацияләү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Төсле металл ватыкларын кабул итү, исәпкә алу һәм реализацияләү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 21 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе әлеге закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 21 октябренә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2297

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 636. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьялары итеп сайларга:

Богачева Надежда Борисовнаны,
Галимова Руфия Рәшит кызын,
Сабиров Марат Мөхәммәт улын,
Сузько Татьяна Николаевнаны,
Хәйруллина Фәридә Вилдан кызын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2298

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 637. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе составындагы үзгәреш турында

С.А.Когогинның Татарстан Республикасы халык депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе составы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге карарына, үзгәртүләр һәм өстәмәләр кертүне алга таба дәвам итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 абзацта:

«Когогин Сергей Анатольевич - 14 нче Зеленодол административ-территория сайлау округы» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2299

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 638. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның июненә кадәр чордагы эше турында хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан 1999 елның июненә кадәр чордагы эше турында хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиленә Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Дәүләт Думасында һәм Федерация Советында федераль конституциячел һәм федераль законнарның проектлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы искәрмәләре һәм тәкъдимнәре үтүен тикшереп торуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2300

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 639. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан алып 1999 елның июленә кадәрге чор өчен хисабы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенең 1995 елның мартыннан алып 1999 елның июленә кадәрге чор өчен хисабын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2301

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 640. Татарстан Республикасы халык депутаты И.С.Абдуллинның «Торак бинасына техник хезмәт күрсәткән өчен түләүнең дифференциацияләнгән ставкалары турында» гарызнамәсе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы халык депутаты И.С.Абдуллинның «Торак бинасына техник хезмәт күрсәткән өчен түләүнең дифференциацияләнгән ставкалары турында» гарызнамәсенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2302

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 641. Татарстан Республикасы халык депутаты С.И.Кириловның «Хәрби хезмәттән запаска яисә отставкага җибәрелгән, республикада яшәүче гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин итү турында» гарызнамәсе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы халык депутаты С.И.Кириловның «Хәрби хезмәттән запаска яисә отставкага җибәрелгән, республикада яшәүче гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин итү турында» гарызнамәсенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 июле
№ 2303

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 642. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен 1999 елның 21 июлендә Казан шәһәрендә дәвам итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2252

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 643. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1998 елда Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында һәм 1999 елның I яртыеллыгында Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау хакында.

«Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

«Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

«Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Мактаулы ана» («Материнская слава») Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Татарстан Республикасының юмалар судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр һәм пикетлар оештыру һәм аларны уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

«Тузган торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе составындагы үзгәреш турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

«Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды судьяларын сайлау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре даими комиссиясе эше турында хисап.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе эше турында хисап.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2253

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 644. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1998 елда Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында һәм 1999 елның I яртыеллыгында Татарстан Республикасының Республика бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау хакында.

«Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

«Мактаулы ана» («Материнская слава») Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

«Митинглар, урамда күмәкләшеп йөрүләр, демонстрацияләр һәм пикетлар оештыру һәм аларны уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне

дәвам итү хакында.

«Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

«Татарстан Республикасының юмалар судьялары турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

«Тузган торакны бетерү өчен максатчыл салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре даими комиссиясе эше турында хисап хакында.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе эше турында хисап хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2254

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 645. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының язгы сессиясенең чираттагы утырышын 1999 елның 14 июлендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2255

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 646. 1999 елның 14 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1999 елның 14 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

2.«Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

3. «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

4. «Кама Аланы» махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

5. «Умартачылык турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

6. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

9. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

11. «Татарстан Республикасы Тукай районының Иске Дөреш җирле үзидарәсенең Яңа Абдул авылын һәм Калмия җирле үзидарәсенең Батрак авылын исәпкә алу

белешмәләреннән төшереп калдыру турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

12. «Татарстан Республикасы Тукай районының Әҗмәкәй җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Яңа торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2256

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 647. 1999 елның 14 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1999 елның 14 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектларын кертергә:

1. «Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

2. «Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

3. «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

4. «Кама Аланы» махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

5. «Умартачылык турында» Татарстан Республикасы Законын кабат карау хакында.

6. «Җирне бәяләү турында» Татарстан Республикасы

законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

7. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

8. «Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

9. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2257

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 648. "Төзелә торган һәм төзелеп беткән индивидуаль торак йортларны (коттеджларны) исәпкә алу, бәяләү һәм теркәү тәртибен бозган өчен физик затларның административ җаваплылыгы турында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе карарын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсене бәяләмәсен исәпкә алып, "Төзелә торган һәм төзелеп беткән индивидуаль торак йортларны (коттеджларны) исәпкә алу, бәяләү һәм теркәү тәртибен бозган өчен физик затларның административ җаваплылыгы турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләп бетерү өчен кабат кайтарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2261

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 649. Татарстан Республикасы Югары суды тарафыннан кертелгән "Татарстан Республикасында юмалар судьялар турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Югары суды рәисе Г.М.Барановның мөрәҗәгатен исәпкә алып, "Татарстан Республикасында юмалар судьялар турында" Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертмәскә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2262

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 650. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июнендәге утырышында Татарстан Республикасы халык депутаталары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июнендәге утырышында Татарстан Республикасы халык депутаталары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты адресына әйтелгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрерг (кушымта итеп бирелә).

Карау нәтиҗәләре турында, бер айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 июле
№ 2264

III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 651. «Татарстан Республикасы икътисады өчен стратегик әһәмияткә ия предприятиеләр акцияләре әйләнешенең аерым тәртибе турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы икътисады өчен стратегик әһәмияткә ия булган предприятиеләрнең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы икътисады өчен стратегик әһәмияткә ия предприятиеләр акцияләре әйләнешенең аерым тәртибе турында» 1997 елның 11 декабрендәге 719 нчы Указына үзгәрешләр кертеп, Татарстан Республикасы икътисады өчен стратегик әһәмияткә ия булган һәм аларның акцияләре әйләнешенә аерым тәртипләр куелган предприятиеләр исемлегенең 15 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«15. Татар икмәк продуктлары» холдинг компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте һәм аның төрдәш акционерлашкан җәмгыятьләре:

«Әгерҗе икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Актаныш икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Арча элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Бөгелмә 1 нче икмәк продуктлары комбинаты» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Бөгелмә 2 нче икмәк продуктлары комбинаты» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Бөгелмә элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Буа элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Борындык элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акцио-

нерлык җәмгыяте;

«Зәй икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Каратун икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Красновидово икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Куйбышев икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Кукмара элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Кулагин» икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Куркачи» икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Мамадыш икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Мөслим икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Яр Чаллы икмәк продуктлары комбинаты» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Яр Чаллы элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Нурлат-Октябрь элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Балык Бистәсе икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Тәтеш икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Чирмешән икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Чистай элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Шәмәрдән икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте;

«Ютазы элеваторы» ачык акционерлык җәмгыяте».

Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Ш□ймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 14 июль
№ УП-567

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 652. Татарстан Республикасы территориясендәге металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгаруны җайга салу чаралары турында

Татарстан Республикасы территориясендәге металл ватыкларын, кара , төсле металл калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгаруга дәүләт контролен көчәйтү, предприятие, оешмалардагы кара, төсле металларны урлауны, промышленность җиһазларын бозуны булдырмый калу, Татарстан Республикасы территориясендәге металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгару белән шөгыльләнүче юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген җайга сала торган хокук законнары базасын камилләштерү, шулай ук Татарстан Республикасының икътисадый иминлеген тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгару эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу турында Татарстан Республикасының тиешле законы кабул ителгәнче юридик затларның әлеге эшчәнлеге, оештыру-хокукый рәвешенә һәм шәхси эшмәкәрлеккә бәйсез рәвештә, билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә металл ватыкларын, кара һәм төсле металл калдыкларын җыю, исәпкә алу, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны читкә чыгару Кагыйдәләренә катгый яраклаштырылган хәлдә, әлеге Указ нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы территориясендәге промышленность, көнкүреш металл калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгару, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган исемлек нигезендә, әлеге эшчәнлеккә юридик хокук бирелгән предприятиеләр, оешмалар һәм шәхси

эшмәкәрләр тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы территориясендәге юридик затларга, оештыру-хокукый рәвешенә һәм шәхси эшмәкәрләргә бәйсез рәвештә, халыктан көнкүреш металл ватыкларын җыю объектларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган исемлегенә кертелмәгән промышленность һәм көнкүреш объектларыннан җыелган металл ватыкларын кабул итеп алу тыела.

3. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына, башка хокук саклау һәм тикшерү органнары белән берлектә, металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын һәм алардан ясалган әйберләрне урлауны, транспорт, төзелеш, электр белән тәэмин итү, сигнал бирү, элемтә чаралары һәм башка объектлардагы җиһазларны урлау фактларын ачыклау юнәлешендәге эшчәнлекне көчәйтергә, шулай ук күрсәтелгән җиһазларның сакланышын контрольдә тоту буенча эзлекле рәвештә оператив профилактика чаралары уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукын яклау дәүләт комитетына бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы территориясендә металл ватыклары, кара, төсле металл калдыклары җыючы,эшкәртүче, реализацияләүче һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгаручы юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең лицензия таләпләрен һәм шартларын үтәүләрен тикшерергә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, халыктан промышленность металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын кабул итеп алу тыелган объектларны исәпкә алуга катгый тәртип урнаштыру хәстәрен күреп, шулай ук, әлеге Указда каралган башка чикләүләрне билгеләп, Татарстан Республикасы территориясендә металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын җыю, исәпкә алу, реализацияләү Кагыйдәсенә бер айдан да соңга калмыйча үзгәрешләр кертергә;

Татарстан Республикасы территориясендә промышленность, көнкүреш металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын җыю, эшкәртү , реализацияләү, шулай ук аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгару белән шөгыльләнергә рөхсәт бирелгән предприятие, оешмаларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең исемлеген расларга;

халыктан җыярга рөхсәт ителгән көнкүреш металл

ватыклары, кара, төсле металл калдыклары объектларының исемлеген расларга;

әлеге эшчәнлекнең лицензияләү өлкәсендәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Икътисад һәм сәнәгать министрлыгына тапшыруны исәпкә алып, әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгәнчә, үзенең лицензияләү эшчәнлеге турындагы норматив-хокук актларын Татарстан Республикасының «Лицензияләү турында» Законына яраклаштырырга;

Татарстан Республикасы территориясендә промышленность, көнкүреш металл ватыкларын, кара, төсле металл калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгару эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу турында закон проектын эшләп, билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының якындагы сессиясе тикшерүенә кертергә;

элек кабул ителгән норматив-хокук актларын шушы Указга яраклаштырырга;

ихтыяҗ туганда әлеге Указның үтәлешен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Икътисад һәм сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Прокуратурасы 1999 елның 1 сентябренә Татарстан Республикасы Президентына әлеге Указның үтәлүенә кагылышлы мәгълүмат биреп, алга таба һәр квартал саен шушы даирәдә хокук бозучылар белән көрәш хакында тиешле материалны җиткереп торырга тиеш.

7. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 14 июль
№ УП-568

# Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен

## Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен